Чүп – чүп мәсьәлә түгел

Чүптән дә күп нәрсә юк хәзер. Шәһәрләр генә түгел, авыллар өчен дә актуаль проблема булып тора ул. Дөрес, кайбер районнарда чүп җыю мәсьәләсе хәл ителгән. Атналар буе җыелган чүпләрен капчыкларга тутырып, капка төпләренә чыгарып куялар да махсус тракторлар аларны районның төп полигонына алып китә. Авыл халкы аның өчен акчаны ай саен махсус тариф буенча түләп бара.

6-7 БИТ

«Кар-бураннарга кереп югалдың, балам...»

Чувашиянең Урмай авылы халкы Хәмдеевләр кайгысы белән яши бу көннәрдә. Айдар – гаиләдә беренче бала. Февральдә 16 яшен генә тутырган булган егет. Әти-әнисе, якыннары, укытучылары гына түгел, бөтен авыл халкы аны мактап туя алмый. Апрель ахырында Айдар күзләрен мәңгелеккә йомган...

11 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 4.05.2017 | № 47 (5809)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«СУГЫШКА АЛГАНДА, БИОГРАФИЯ СОРАМАДЫЛАР»

Аны сугышка 17 яшендә алалар.

– Сугышка киттем дип сөйләсәм, дөрес булмас. Алдылар дип әйтим, – дип искә ала 1943 елның июнь иртәсен Балтач районы Түбән Кенә авылында яшәүче Тәскирә Галимуллина. – Хәзер уйлыйм, авыл советына нәрәт килгәндер дә иң беренче чиратта безнең гаилә торгандыр. Кагылулы булдык шул без. Әтиебез колхоз председателе иде, аны сугыш башланганчы кулга алдылар. Без, аннан халык дошманы ясаганнар, дип тә белмәдек. Бик яшь идек шул әле...

10 БИТ

Реклама

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 69 сум 31 тиен

3 айга 207 сум 93 тиен

6 айга 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язылу!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен 1 айга

427 сум 14 тиен 3 айга

854 сум 28 тиен 6 айга

РЕСПУБЛИКАДА

ӘЛМӘТ

Нефтьчеләр башкаласында балалар технопарксы ачылачак. «Кванториум» югары технологияле җиһазлар белән тәэмин ителгән балалар иҗаты үзәге булырга тиеш, дип яза район газетасы. Балалар биредә хуҗалык эшләрен алып бару, өс киемнәре тегү һәм кисү, ботаника түгәрәкләренә һәм зоотүгәрәккә йөри алачаклар. Моннан тыш, технопаркта сәнәгый дизайн, ИТ-квант, наноквант, нейроквант, кул эшләре иҗаты һәм рәсем сәнгате кабинетлары, китапханә, шулай ук коворкинг һәм робоквант кабинетлары булачак.

ЧИРМЕШӘН

Бөек Җиңүнең 72 еллыгын каршылаган көннәрдә Чирмешән районының Бөек Ватан сугышы ветераннарына Татарстан Президентының бүләкләрен тапшырганнар. Район башлыгы Фердинат Дәүләтшин 92 яшен тутырган Александр Чупахинга Президент күчтәнәчләрен һәм шәхсән үзенең бүләкләрен өенә илтеп биргән.

КУКМАРА

Авария хәлендәге йортларда яшәүчеләрнең торак шартларын яхшырту максатыннан, Кукмара районының Лубян авылында республика программасы буенча яңа йортлар төзелә. Завод урамындагы дүртәр фатирлы биш йорт тиздән куллануга да тапшырылачак. Биредә инде су кертелгән, канализация дә үткәрелгән.

ӘГЕРҖЕ

Әгерҗе районы мәдәният сараенда балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр арасында беренче тапкыр «Мин – татар малае, мин – татар кызы» бәйгесе узган. Анда сигез бала катнашкан.

САРМАН

Республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов Сарман районындагы язгы кыр эшләренең барышы белән танышкан. Тармак җитәкчеләре, белгечләре, авыл җирлекләре башлыклары белән очрашканчы, министр муниципаль район башлыгы Фәрит Хөснуллин белән вертолеттан басуларны карап әйләнгән. Сөйләшү барышында ул күргәннәреннән канәгать булуын белдергән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ИГЕЛЕК ҖИРДӘ ЯТМАС

Узган атнада «Пирамида» концертлар залында «Ел хәйриячесе – 2016» республика бәйгесе җиңүчеләрен тәбрикләделәр.

Бәйге унынчы тапкыр уздырылды. Шушы еллар эчендә хәйрия максатларына 28,5 млрд сум акча юнәлтелгән. Республикадагы хәйрия оешмаларының саны да 250гә якын. Бүләкләнүчеләрнең дә елдан-ел арта баруы хәйриячелек кылу һәр кешенең күңелендә дә, тормышында да билгеле бер урын алып торуы турында сөйли. Мәсәлән, әле узган ел гына аларның саны 70 булса, быел 93 кеше «Ел хәйриячесе» булды. Бүләкләнүчеләр арасында «Шәһри Казан» газетасы да бар.

– Бүген без бик матур изге эшләргә нәтиҗә ясарга җыелыштык, – диде җиңүчеләрне тәбрикләгәндә шушы бәйгенең башлангычында торган Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев. – Моннан ун ел элек, әлеге үзгәртеп кору елларында, без бу эш белән шөгыльләнә башларга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Әмма әлеге эшләр шактый еллар алданрак башланды. Иң мөһим вакыйга булып «Кол Шәриф» мәчетен һәм Благовещенский соборын торгызу тора. Ул елны Аллаһы Тәгалә дә безгә мул уңыш бирде. Хәйрия мәсьәләләре буенча республика фондына 31 млрд сум акча җыелды. Аның башлангычы менә шунда ята. Шулай ук легендар хәйрияче Әсгать Галимҗановның изге эшләре дә үрнәк булып тора. Бүген монда җыелган хәйриячеләргә зур рәхмәт. Изге эш җирдә ятмый.

«Хәйрияче гражданин» номинациясендә җиңү яулаган Рөстәм Мингазиев, мәсәлән, Апас районының Иске Йомралы авылы яшьләре арасында җиде ел дәвамында хоккей турнирлары үткәреп килә. Аннан соң авыл зиратын, мәчетен төзекләндерүгә дә үзеннән зур өлеш керткән кеше ул.

– Күңел яхшылык эшләүгә омтыла. Алда да эшлисе эшләр күп әле, – диде ул безгә.

Тантананың иң ахыргы өлешендә хәйриячеләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәбрикләде.

– Хәйриячелек ул һәрвакыт безнең белән булды. Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә Благовещенский соборы һәм «Кол Шәриф» мәчете торгызыла башлаганда, мин Биектау районы башлыгы булып эшли идем һәм бу чараларның шаһиты булдым. Ул чакта хәйрия эшчәнлегенә эшкуарлар да, гади гражданнар да бик теләп кушылды. Әсгать абый бүген безнең арада юк. Никадәр яхшы гамәлләр кылган гап-гади кеше иде ул. Киләчәктә аның исеме белән бәйле берәр номинация булдырырга кирәк. Андый үрнәк кешеләр безнең күңелләрдә озак сакланырга тиеш, – диде ул.

Җиңүчеләр арасында «Массакүләм мәгълүмат чаралары» номинациясендә җиңү яулаган «Шәһри Казан» газетасы да булу – үзе бер сөенеч һәм горурлык.

– Соңгы вакытта без коллегаларым – журналистлар белән массакүләм мәгълүмат чараларына ышаныч турында күп сөйләшәбез. Бу бик мөһим, әгәр журналист сүзенә ышаныч булмаса, безнең барлык акыл, физик, матди, рухи көч сарыф итүебез бушка булыр иде. Хәйриячелек белән шөгыльләнү дә, бу эшләрне яктырту да безнең профессиягә намуслылык өсти. Шушы матур бәйгедә журналистларга багышланган номинация булуына бик шатмын, – диде Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен котлап.

Тантаны алып баручы – танылган кино актеры һәм телевидение алып баручысы Александр Олешко да сәхнәдәге хис-кичерешләргә түзмәде, тантана ахырында Президент Рөстәм Миңнехановка вәгъдә бирде: «Мин Казанның теләсә кайсы залында хәйрия концерты уздырырга телим. Анда керү бушлай булачак», – диде ул.

Зәһрә САДЫЙКОВА.

Шәһәр кәефе

БӘХТИЯР САБИРОВ,
журналист:

– Казанның Суконка бистәсе малае мин. Шәһәр үзәгендәге агач өйләрдән торган шул авылны еш искә алам. Башкаланың һәр районында үзенчәлекле агач өйләрне саклап калырга кирәк, минемчә. Иске Татар бистәсендә агач өйләрне борынгы рәвешендә торгызуны бик хуплыйм. Вакытлы матбугатта хезмәт юлымны башладым гына әле. Максатым – һөнәри осталыкка ирешү. АКШка һәм Гонконгка да барасы килә, ләкин болары – ерактагы хыял.

ФӘРИДӘ ЯКУШЕВА,
мөхәррир:

– Үзбәкстанның Фиргана үзәнлегендә туып-үстем. Олы апам Әлмәттә эшли иде, унбиш яшемдә мин дә Татарстанга килдем һәм шушында икенче туган илемне таптым. Казанда 1983 елдан яшим. Шәһәребездә яңа салынган йортларны тимер рәшәткә белән уратып алуларын яратмыйм. Янәшәдәге йортларга ишегалды калмый диярлек. Парашюттан сикергәнем бар, канда адреналины һаман кайный әле. Хәзер үзем генә дельтопланда очарга исәп.

ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВ,
укытучы-галим:

– Тумышым белән Актаныштан. Тәтеш җир төзелеше техникумы 1954 елда Казанга күчерелде. Шул техникумның студенты буларак, мин дә башкалага күчендем. Казанда татарлык, милли төсмер үстерелсен иде. Чит ил кешеләре җирдә казынмасалар казынмасыннар. Без һәркайсыбыз бакчаларыбызда яшелчәләрне һәм җимеш агачларын күпләп үстерик. Россиянең төньяк төбәкләрендәге питомниклар үсентеләрен утырту кирәк, чөнки алар салкынга чыдам.

ХӘЛИМӘ ХӘКИМОВА,
китапханәче:

– Красноярск краендагы Однушка бистәсендә яшибез. Татар авылы ул, борынгы исеме – Тәркеш. Ана телебезне саклыйбыз, татарча сөйләшәбез. Биш яшемдә чакта әти-әнием белән Казанга килгәнем бар иде. Татар җәмәгатьчелегеннән бер төркем Казанга корылтайга чакырылдык. Бик шатландык, Татарстанга, Мәдәният министрлыгына рәхмәт! Казан соклангыч матур, төзек. Кызганыч, кайбер татарлар үз ана телен белми икән монда.

ШӘМСЕТДИН ГАЙФИЕВ,
машина йөртүче:

– Балта остасы да, мич чыгаручы да инде мин. Аллаһ Тәгаләгә ышанам, һәр эшемне бисмилла әйтеп башлыйм. Казанның үзәк урамнарында хәер соранучылар йөртелмәсен иде. Мин үзем Балтач районындагы Нөнәгәр авылында яшим. Бер караганда, хәер соранучылар минем эш түгел. Шунда ук чит ил туристлары йөри, алар алдында оят. Яр буйларына чүп түгелүенә җаным әрни. Суларны пычрату бик олы гөнаһ, диелгән бит.

«Үлемне каршы алырга әзерләндек»

Мәскәүдән Бангкокка 9 сәгать очкан «Аэрофлот» компаниясенең «Боинг 777» самолеты тиздән «Суварнапхум» аэропортында утырырга тиеш булган. 40 минут кала, экипаж пассажирларга бар да яхшы икәнен һәм Бангкокта нинди һава торышы көткәнен хәбәр итә.

Тик кинәт самолет турбулентлык зонасына эләгә һәм очкыч эчендә кешеләр, сумкалар, ашамлыклар, хәтта утыргычлар оча башлый. Бер минутка якын вакыт эчендә 27 пассажир җәрәхәт ала, алар арасында Уфадан Гөлназ Хәлфина да була. Ул тормыш иптәше белән май бәйрәмнәрен диңгез буенда уздырырга планлаштыра.

– Очкыч тыныч кына барган иде. Миграция карточкаларын тутырып утырганлыктан, куркынычсызлык каешын эләктермәгәнмен… Бервакыт самолет зур тизлек белән аска төшә башламасынмы?! Карыйм, кем чукына, кем бисмилла укый… Үлемне каршы алырга әзерләнә башладык. Мине кинәт өскә чөйде, башымны бәрдем һәм берникадәр һушыма килә алмый яттым. Аңыма килгәч, кулларым һәм борыным сынганлыгы билгеле булды. 20 минуттан соң самолет аэропортта тыныч кына утырды һәм безне ашыгыч ярдәм табиблары каршы алды. Бангкок хастаханәсендә кул сөякләремне кисәкләрдән җыйдылар. Әлегә бернәрсә дә эшли алмыйм. Хәлем бераз яхшырса, бер атнадан Россиягә кайтарып җибәрергә тиешләр. Моңа кадәр дә очкычларга утырырга курка идем, аннан соң йөз кат уйлаячакмын инде, исән-сау туган ягыма гына кайтып җитим… – дип сөйләде ул «ШК» хәбәрчесенә.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

Турбулентлык яки болгану – кимеп һәм көчәеп бара торган вермәле җил агымына эләккән вакыттагы самолет тирбәлеше. Аның да төрлесе була. Кайбер төр болытлар аркылы очканда тирбәлгән самолетка бернинди дә куркыныч янамый. Моннан тыш, очкыч аяз күк йөзендә дә селкенергә мөмкин. Гадәттә, бу күренеш бик биек булмаган – 500-600 метр биеклектә күзәтелә. Ә менә яшенле болытлар вакытында мондый зонага эләгү чыннан да бик зур күңелсезлекләр белән тәмамланырга мөмкин. Шуңа күрә бортпроводникларның һәм яктыртылган таблодагы киңәшләргә колак салыгыз, урыныгызга утыргач, куркынычсызлык каешларын эләктерергә онытмагыз.

Эшнең кайнаган чагы

Рәхәтләнеп җиң сызганып эшли торган чорга аяк бастык. Бигрәк тә авылларда бу вакытта тулы куәтенә эш кайный. Май башындагы елларны да халык гадәттәгечә эшләп «бәйрәм итә». Берәүләр өй юа, бакча, тирә-юньне тәртипкә китерә, икенчеләр баздан бәрәңге чыгара, шушы көннәрдә терлекләрне дә көтүгә чыгаручы районнар бар. Кыр эшләренең дә кызган чагы. Игенчеләр күпьеллык үләннәрне, уҗымнарны тукландыра-тырмалый, сөрелгән җирләрне эшкәртә, көне-төне кырда тир түгә – чәчүдән кайтып керми. Язның бер көне ел туйдыра, дип белми әйтмәгәннәр шул.

Ә СЕЗ НИ БЕЛӘН МӘШГУЛЬ?

Сания ДӘҮЛӘТШИНА,
Мамадыш районы:

– Балалар май бәйрәмендә өйләрне җыештырды, кишер, чөгендер чәчте, сарык йонын алдылар. Бәрәңге утыртырга бераз иртәрәк әле дидек. 9 майларга көтү дә чыгарга тиеш, Алла боерса. Бездә сыер белән сарык көтүе аерым-аерым көтелә. Узган елларны сыерларны электрокөтүче көткән иде. Быел сарыкка да шулай итмәкчеләр. Узган ел электрокөтүченең бәясе кеше башына 2 мең сум булды. Быел ничек буласы әлегә билгесез. Алда зур эш булып өй юу тора. Аннысын Уразага кергәнче май ахырларында башкарып чыгарбыз дип торабыз.

Наилә АБДУЛХАЕВА,
Казан:

– Киндеридәге бакчабызда эшләр башланды инде. Агачларны акладык, кишер, суган утырттык. Алдагы елларны, гадәттә, бу вакытларга бәрәңге утырта торган идек инде, әмма быел башка эшләр килеп чыгу сәбәпле, өлгерә алмый калдык. Күрше-тирәбездәге бакча хуҗалары арасында утыртучылар бар. Без дә шушы атна ахырында әлеге эшне башкарып чыгарбыз дип торабыз.

Әлфия КӘЛИМУЛЛИНА,
Яшел Үзән районының
Кече Ачасыр авылы:

– Без авылга әти-әниләр янына җәйге чорда гына кайтканлыктан, терлекләр, кош-кортлар тотмыйбыз. Шуңа күрә күбрәк ишегалдын җыештырып, бакча казып, мунча юып уздык елларыбыз. Күрше авылларда бәрәңге утыртучылар да бар. Гомер-гомергә авылдагы көтүне чиратлап көтәләр иде. Быел көтүче ялладык, диделәр. Бер сыер башына 700 сум түлисе икән. Авылыбыз бик кечкенә. Күбесенчә өлкәннәр яши, шуңа күрә сыер тотучылар да бик аз.

Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА,
Азнакай районының
Беренче Май авылы:

– Авылда эш бетми инде ул. Көн туды исә абзарда тирес түгәбез, ишегалларын җыештырдык, мунчаларны юдык, бакчада түтәлләр ясадык, кишер чәчтек. Суган утыртырга иртәрәк әле, дибез. Баздан бәрәңге чыгардык. Анысын 10-20 май аралыгында утыртырга киңәш итәләр. Бүген менә беренче көн көтү чыкты. Мал табиблары терлекләрдән кан алды. Бездә көтүче яллыйлар. Бер сыерга 400 сум түлисе. Күрше авылларда чиратлап көтүчеләр дә, сыер башына 1000 сумга яллаучылар да бар. Безнең якларда күпләп мал асрыйлар. Көтүгә бер йорттан тугыз, хәтта 15-20 мөгезле эре терлек чыгаручылар бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

ТОП – 3

«БИГЕШ» аэропорты сайтындагы мәгълүмат нигезендә, 2017 елның май-июнь айларында, ягъни озын тәнәфестән соң Анталия төрек курортына рейслар җәйгә салыныр дип көтелә. Шулай ук Россиянең көньяк курорт зоналарына да: Сочи, Симферополь, Анапа шәһәрләренә рейслар булдырылачак. Май аенда Мәскәүнең Шереметьево аэропортына да очышлар ешлыгын атнага алты рейска кадәр арттыру көтелә.

ТАТАРСТАН, Россиянең башка субъектлары белән берррәттән, заманча шәһәр тирәлеген булдыру программаларына акчалата ярдәм алачак. Бу хакта Россия премьер-министры Дмитрий Медведев имзалаган карарда әйтелә. Федераль бюджеттан бүлеп бирелгән гомуми акча күләме 5,1 миллиард сумны тәшкил итә. Татарстан 1,09 миллиард сум алачак. Әлеге акчаларны мәйданчыклар, яр буе, урамнар, җәяүлеләр зоналары, парклар, ишегалларын һәм муниципаль берәмлекләрнең территорияләрен төзекләндерүгә тота ала.

ПРЕМЬЕР-МИНИСТР Дмитрий Медведев эшләүче пенсионерларның пенсияләрен өстәмә индексацияләү турындагы мәсьәләне эшләү буенча йөкләмә бирде. Сүз эшләүче пенсионерларның пенсияләрен индексацияләүнең элеккеге схемасына кайту турында бара. Әлеге мәсьәләдә Россия Хезмәт һәм социаль яклау, Финанс, Икътисади үсеш министрлыклары һәм Пенсия фонды икътисади-финанс ягыннан дәлилләнгән күзаллавын 2017 елның 24 маена кадәр тәкъдим итәргә тиешләр. Бу хакта «Российская газета» хәбәр итә.

САН

*2 майга республикада **55 034** сугыш ветераны исәпләнә. Аларның саны узган елга караганда **10 меңгә** кимрәк.*

АБАУ!

Ходайдан да курыкмыйлар

Яшел Үзән районы Бәчек авылы халкының тетрәнү кичергән көннәре. Биредә зиратта инде өченче мәртәбә кабер ташларына зыян салалар. 2012, 2014 еллардагы хәлләрдән соң бераз тынычланган халыкның йөрәк җәрәхәте кабат яңарган. 30 апрель көнне авыл халкы кайсы аударылган, кайсы җимерелгән 93 кабер ташына тап булган. Вандаллык актлары алдагы ике очракта да язын эшләнгән иде.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанның җиде театры федераль бюджеттан финанс ярдәме алачак, дип хәбәр итә республиканың Мәдәният министрлыгының матбугат хезмәте. Сүз «Бердәм Россия» партиясе инициативасы белән тормышка ашырыла торган кече шәһәр театрларына грантлар бирү проекты турында бара. Әлеге максаттан Башкортстан Республикасының кече театрларына 34,8 млн сум акча киләчәк. Исемлектә Туймазы татар дәүләт драма театры да бар.

Чабаксарда Бөек Ватан сугышы ветераннары 3-12 май көннәрендә бөтен төр җәмәгать транспортында бушлай йөри алачак. Шулай ук бу мөмкинлектән аларны озата баручылар да файдалана алыр дип планлаштырыла. 9 майда ветераннарны бәйрәм чаралары уза торган мәйданнарга ун автобус алып барачак. Аларның һәрберсендә медицина хезмәткәре эшләр дип уйланыла.

Мари Эл республикасында сезон башыннан өч урман территориясендә янгын чыккан. Нәтиҗәдә 6 гектардан артык мәйданга зыян килгән. Янгынның ике очрагындагы сәбәп – ял итүчеләрнең ут белән саксыз эш итүләре. Мари Эл республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы искәртүенчә, 15 майга кадәр урманнарга керү тыелган.

Җитәкчеләрнең акчаларын санныйбыз

Дәүләт хезмәткәрләре 2016 елга керем декларацияләрен тапшырды. Кеше акчасын санарга ярамый, диме әле халык мәкале? Анысы шулай, кеше акчасында кемнең ни эше бар. Тик менә сүз түрәләрнең еллык кереме турында барганда, үзеннән-үзе саныйсы килә башлый.

Эльвира МОЗАФФАР

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов салым хезмәтенә тапшырган еллык керем декларациясе нәтиҗәләре буенча, 2016 елда 7,5 миллион сум акча эшләгән. Узган ел белән чагыштырганда, бу сумма 24 процентка күбрәк булса да, тормыш иптәшенекен куып тота алмаган. Гөлсинә ханымның былтыргы кереме – 2,35 миллиард сум. Аның исемендә шактый күчемсез милек исәпләнә: 263,2 квадрат метрлы торак йорт, 414 квадрат метр һәм 1776 квадрат метр мәйданлы җир кишәрлекләре, кунак йорты, Берләшкән Гарәп Әмирлегендә мирас буенча калган фатир, парковка урыннары...

Гомумән, 2016 елга керем турында тапшырылган декларацияләр буенча күп җитәкчеләрнең хатыннары үзләренә караганда күбрәк акча эшләгән. Татарстанның гадәттән тыш хәлләр һәм гражданнарны саклау министры Рафис Хәбибуллин үзе 3,2 миллион сум гына керем алса, хатыны гаилә бюджетына 41 миллион сум өстәгән.

Сәламәтлек саклау министры Адел Вафин, алдагы ел белән чагыштырганда, былтыр ике тапкырга диярлек азрак акча эшләгән – 3,57 миллион сум. Аның каравы, хатыны 7,8 миллион сум керем алган, Audi машинасын Mercedes-Benzка алыштырган. Сүз уңаеннан, Әсгать Сәфәровның хатыны да BMWдан Lexuska күчкән. Президент аппараты җитәкчесе былтыр 9,2 миллион сум акча эшләгән.

Президентның ярдәмчеләренә килгәндә, Олеся Балтусова 4 миллион сумга якын акча эшләсә, Наталия Фишманның хезмәт хакы сер булып кала. Ул үз вазифаларын штаттан тыш хезмәткәр буларак башкара, дип яза «Бизнес онлайн».

Министрлар арасында иң күп акча эшләүче – Артем Здунов, икътисад министры. Ул ел дәвамында 8,5 миллион сум керем алган. 2015 елда 6,2 миллион булган. Былтыр министрның милкенә ике җир кишәрлеге өстәлгән. Ә менә сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримовның кереме, алдагы ел белән чагыштырганда, шактыйга кимегән. 2015 елда 29 миллион сум булса, 2016 елда 6,7 миллион сум гына. Югыйсә, милкендә дә әллә ни үзгәреш тә күзәтелми, шәхси тормышы да элеккечә – өйләнмәгән, баласы бар.

Алексей Песошин исә быел беренче тапкыр премьер-министр буларак керемнәре турында хисап тотты. Югыйсә, ел дәвамында ул премьер-министр урынбасары хезмәт хакын алып эшләде. Нәтиҗәдә, былтыр ул 4,3 миллион сум акча алган. Гаилә керемен 1,2 миллион сум белән Казан Башкарма комитетында эшләүче хатыны Лариса Песошина тулыландыра. Песошинның милкендә фатир, «Стингрей» көймәсе, «Тохатсу» моторлы көймәсе исәпләнә. Хатыны исеменә ике җир кишәрлеге, торак йорт һәм фатир теркәлгән. Россиянең премьер-министры Дмитрий Медведев исә былтыр 8,5 миллион сум акча эшләгән. Еллык керем турындагы декларация буенча хатыны 2016 елда бер тиен дә эшләмәгән.

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ
Татарстан Президенты
7 509 325,55 сум (2016)
2015 елга керем 6 067 343,94 сум

Владимир ПУТИН
Россия Президенты
8 858 432 сум (2016)
2015 елга керем 8 891 777 сум

Фәрит МӨХӘММӘТШИН
Дәүләт Советы рәисе
11 313 957,58 сум (2016)
2015 елга керем 11 663 095,37 сум

Алексей ПЕСОШИН
Премьер-министр
4 315 813, 27 сум (2016)

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

Вячеслав ЗУБАРЕВ
«ТрансТехСервис» идарәче компаниясе оешмасының директорлар советы рәисе, Дәүләт Советы депутаты
641 281 251,81 сум (2016)
2015 елга керем 36 742 515,41 сум

Равил ЗИГАНШИН
«Казан» җитештерү тәэлеш берләшмәсе генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты
163 549 973,29 сум (2016)
2015 елга керем 71 667 839,54 сум

Мөслимә ЛАТЫЙПОВА
«Бәхетле1» җәмгыяте генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты
109 777 832 сум (2016)
2015 елга керем 153 348 554 сум

Рөстәм САБИРОВ
«Татнефтепродукт» холдингының генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты
101 010 172,0 сум (2016)
2015 елга керем 1 801 319 493 сум

Рөстәм ХӘЛИМОВ
«Татнефть» оешмасының нефть һәм газ җитештерү буенча генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты
89 765 129,24 сум (2016)
2015 елга керем 67 706 782,98 сум

Иң аз керем

Ксения ВЛАДИМИРОВА
«Бердәм Россия» партиясе тарафдарлары төбәкара координацион совет рәисенең урынбасары, Дәүләт Советы депутаты
943 191,50 сум (2016)
2015 елга керем 455 355,86 сум

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ

Артем ЗДУНОВ
Икътисад министры
8 539 097,82 сум (2016)
2015 елга керем 6 200 010,09 сум

Альберт КӘРИМОВ
Премьер-министр урынбасары, сәнәгать һәм сәүдә министры
6 788 772,08 сум (2016)
2015 елга керем 29 318 003,05 сум

Азат ХАМАЕВ
Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры
6 601 151,65 сум (2016)
2015 елга керем 6 659 262,26 сум

Васил ШӘЙХРАЗИЕВ
Премьер-министр урынбасары
6 554 472,42 сум (2016)
2015 елга керем 12 629 024,52 сум

Роман ШӘЙХЕТДИНОВ
Премьер-министр урынбасары, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры
5 693 244,26 сум (2016)
2015 елга керем 7 546 536,53 сум

Федор БАТКОВ
Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе җитәкчесе
5 649 998,90 сум (2016)
2015 елга керем 2 669 779,12 сум

Иң аз керем

Ирада АЮПОВА
Татарстанның архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе
2 548 915,15 сум (2016)
2015 елга керем 1 433 710,32 сум

«Үлемсез полк»ка кушылыйк

Казанда «Үлемсез полк» илкүләм акциясен үткәрү вакыты билгеләнде. Парад 9 майда 15.00 сәгатьтә узачак. Татарстанның Иҗтимагый палата рәисе урынбасары, «Россиянең үлемсез полкы» хәрәкәтенең төбәк штабы җитәкчесе Тимур Халиков хәбәр итүенчә, барлык маршрут озынлыгы 2 чакрымнан артыграк булачак. «Полк»ның башында «Союз – Җиңү варислары» халыкара яшьләр белем бирү проектында катнашучылар булыр дип уйланыла. Россия шәһәрләренең 50дән артык шәһәреннән 600ләп кеше 200 квадрат метрлы мәйданда Җиңү Байрагын күтәреп барачак. Узган елдан аермалы буларак, быел Меңьеллык мәйданында мең кешелек «Җырлаучы Казан» хорының чыгышы, гаять зур интерактив бәйрәм программасы көтә.

Быел парадта якынча 100 мең кеше катнашыр дип көтелә. Акцияне оештыруда 500 волонтер җәлеп итәргә ниятлиләр.

Яшьләрдән – ветераннарга

Инде биш ел рәттән «Отечество» белән «Курс» иҗтимагый яшьләр оешмасы Җиңү паркында алмагачлар утырта. Бу «Хәтер аллеясы» Бөек Ватан сугышы вакытында яу кырында ятып калганнар, Әфган, Чечня, Грузия, Сүриядә барган бәрелешләрдә һәлак булганнар истәлегенә үсә.

«Шигырьләр аша сугыш» («Война в стихах») акциясе кысаларында, яшьләр әдәбиятның «көмеш чоры» шагыйрьләренең Ватанга багышлап язган 30 әсәрен әзерли. Беренче тапкыр әлеге чара Бөек Җиңүнең 70 еллыгына оештырылган иде. Ул вакытта активистлар сугыш турында 70 шигырьне сәнгатьле итеп сөйләп, видеотасмага яздырды. Видеотасмалар социаль челтәрләрдә таратылачак. Әсәрләр көнтөн интернетта утыручы яшьләргә барып җитәр, аларда ватанпәрвәрлек рухы уятыр дигән өметтә кала оештыручылар. «Җиңү волонтерлары» да үзенчәлекле патриотик дәрес алып бара. Алар сугыш ветераннары каберләрен барлый, караучысыз калган каберләрне тәртиптә тота. Шулай ук яшьләр бу каберләрнең координаталарын билгеләп бөтенроссия электрон картасына урнаштыра. Хәзер һәйкәлләр, мемориаль такталар белән бергә һәр ветеранның кайда күмелгәнлеген интернет аша гына да карап булачак.

Быел беренче тапкыр Казан Кремле инициативасы белән 9 май көнне Тупчы мәйданында иртәнге сәгать 11дән кичке 7гә кадәр активистлар «Җиңү көне» җырын башкарачак. Теләгән һәр кеше әлеге чарага кушыла ала.

Алисә САБИРОВА.

Яшьләр оештырган башка чаралар:

5 МАЙ
Ветераннар өчен концерт Сугыш ветераннары госпитале (Исаев урамы, 5).

6 МАЙ
«Җиңү көе» республика оркестрлары чыгышы Кремль яр буенда.

7 МАЙ
«Җиңү көне» флешмобы (Казан Кремле).

8 МАЙ
Бөтен республика ветераннары өчен зур концерт (Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры).

9 МАЙ
«Үлемсез полк» акциясе.

АВЫЛ

Сафиннар гаиләсе

ӘЛКИ УҢГАННАРЫ

Татарстанның төрле районнарында булырга туры килсә дә, Әлки якларына барганыбыз юк иде әле. Бер күрүдә үк яраттык әлкилеләрне. Халыкның тырышлыгына, бердәмлегенә сокланып кайттык.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан – Әлки районы, Иске Камка

ЮЛ БУЛСА, АВЫЛ ЯШИ

Иске Камка җирлегенә Карамалы, Яңа Камка авыллары керә. Иске Камка үзе район үзәге Базарлы Матактан 15 чакрым ераклыкта урнашкан. Риваятьләр буенча, 1611 елларда Пенза якларындагы Камка авылыннан күченеп килгән бер бабай авылга нигез салган. Соңрак авылдан берничә хуҗалык аерылып чыгып, Карамалы авылын булдырган. Шул рәвешле Яңа Камка авылы да барлыкка килгән. Иске Камка дигәнендә 212 кеше исәпләнә. Яшәр өчен барлык шартлар да тудырылган. 2012 елда Президент Рөстәм Миңнеханов килгәч, җирле үзидарә башлыгы Фәргать Әкбәров, уңайсызланып булса да, юл мәсьәләсен кузгаткан. Бер ел дигәндә, Иске Камканың үзәк урамына юл салганнар. «Асфальт салындымы, юл бармы – димәк, авыл яши», – ди Фәргать абый. Үзара салым акчасына калган урамнардагы юлларны да рәткә китерәләр, йортларга үткәрелгән су торбаларын яңартырга уйлыйлар. Йортларның 80 процентында бәдрәф – өйдә. Урам баганаларында утлар яна. Үзәктә яңа мәдәният йорты төзелеп килә. 50 ел элек булган, инде кибеп барган күлне дә төзекләндергән авыл халкы. Хәзер анда балык үрчетергә уйлыйлар. Дөрес, авылда 30 яшькә чаклы гаиләләр дүртәү генә. Урта мәктәпне дә 2010 елда ябарга туры килгән. 14 бала 10 чакрым ераклыктагы күрше Алпар мәктәбенә барып укый. Аның каравы, авылда сакланып калган, хәзер инде башлангыч мәктәп буларак хезмәт иткән бина бик төзек. Китапханә, авыл үзидарәсе дә шунда урнашкан. Тиздән балалар бакчасы ачарга ниятлиләр.

– Балалар саны кимегәч, бакча ябылган иде. Быел менә мәктәпкәчә яшьтәге тугыз бала җыелды. Шуңа да, район белән берлектә, балалар бакчасын кабат ачарга кирәк дип карар иттек, – ди үзидарә башлыгы.

«ЯХШЫ. НОРМАЛЬНО. ЗЫЯН ЮК»

Авылда инвесторлар халыкны эш белән тәэмин иткәннәр. Үз фермерлык хуҗалыкларын булдыручылар да бар. Шуларның берсе – Сафиннар гаиләсе.

– Кая барсам да, бу парны күпләргә үрнәк итеп сөйлим. Тумыштан инвалид булсалар да, Бриллиант белән Рамил Сафиннар үз эшләрен булдырдылар. Кайбер сау-сәламәт кешеләр дә әзергә бәзер булып яшиләр. Ялкауланалар, китереп биргәнне көтәләр. Ә менә бу пар беркайчан кул кушырып утырмый, – ди авыл башлыгы Фәргать Әкбәров, сыйныфташы Рамил абый өчен шатланып.

Ул аның мәктәп елларыннан ук сату-алуга оста булуын хәтерли. 1981 елда ук Чистай базарына барып, сарык йоны саткан. Питрәч районыннан авыл халкына чебешләр алып кайтып бирә торган булган.

Үзенчәлекле исемле Бриллиант ханым – Лениногорск районының Каратай авылы кызы – ире Рамил белән газетадагы игълан аша танышкан. Өч еллап хат алышканнан соң, язмышларын уртак итеп, өйләнешергә булганнар. Быел бергә гомер итә башлауларына – 17 ел. Гаилә башлыгына – 51 яшь, хуҗабикә дә 46ны тутырып килә. Аллаһының кодрәте белән, тупырдап торган сау-сәламәт ике ул үстерәләр. Быел олы уллары Ранил тугызынчы сыйныфны тәмамлап, укуын шәһәрдә дәвам итәргә уйлый. Рәзилгә әле ике генә яшь.

Сафиннар өч сыер асрыйлар. Бриллиант ханым сөт продуктларын әзерли, ир аларны көн саен Базарлы Матакка алып барып сата. Үз сатып алучылары аның килгәнен көтеп кенә тора.

– 45 литрлап сөт, 3 савыт каймак, 3 кило тирәсе эремчек берничә сәгатьтә сатылып бетә. Көн саен 1500 сум тирәсе акча кереп бара. Яхшы. Нормально. Зыян юк, – дип елмая Рамил абый.

Әле 8,2 гектар җир алган. Анда печән үстерергә җыена. Күптән түгел 320 меңгә трактор, аңа авыл хуҗалыгында киң кулланыла торган кун сатып алган. Сыерларны ашатырга азык үзендә булачак дигән сүз. Бәрәңге, яшелчәләр дә утырталар. Тәрәзә төбендә шаулап үскән помидор үсентеләре көннәр җылынганны көтә.

Рамил абыйның әнисе Зәйтүнә апага улын мактыйбыз. «Шулай булырга тиеш», – ди Зәйтүнә апа. 80 яшеннән узса да, үзенең дә эшсез торганы юк. Былтыр гаилә 200 баш каз үстергән.

Сафиннарның йортларында бар җирдә дә чисталык, пөхтәлек. Күптән түгел ремонт ясатканнар.

– Балалар – Аллаһы Тәгалә биргән бүләк. Улларыбызның исән-сау булып тууы – могҗиза. Киләчәктә дә бәхетләре булсын. Игелекле булып үссеннәр, – дип тели әти-әниләре.

ФЕРМА УРЫНЫНА СӨТ

Әлкидә 28 гаилә фермасы санала. Шулар арасында Сергей Рыжковның хуҗалыгы аеруча аерылып тора. Ул – чуваш авылы Түбән Калчугинодан. Төрле өлкәләрдә эшләп караганнан соң, тәвәккәлләп, үз эшен булдырган – 20 сыер алган. Әлкидә танылган эшмәкәр Дамир Шәйдуллин ярдәмгә килгән. Алыш-биреш килешүе буенча, Рыжковларга мини-ферма төзеп биргән, ә Сергей аңа хәзер бурычын түли – сөт тапшыра. Бер-берсенә ярдәмләшеп эшләүче фермерлар Әлкидә җитәрлек. Үз эшен яңа башлаган хуҗалыклар өчен бу – бик мөһим ярдәм, дип саный үзләре.

Сергей Рыжковның фермасында бар да заманча эшләнгән. Савылган сөт махсус торбалар аша суыту цехына китә.

– Тиздән монда, сөткә шикәр комы кушып, туңдырма да ясап булачак, – дип шаярта Әлки районы авыл хуҗалыгы идарәсенең җитештерү бүлеге мөдире Фәрит Вәгыйзов.

Фермадагы мондый чисталыкны күпме авылларда булып та күргәнебез юк иде әле. Бар нәрсә тәртиптә, көн яңгырлы, юллар пычрак булуга карамастан, сөт ташый торган машина да ялт итеп тора. Ферма тирәсендә тәмәке тартырга да рөхсәт итми хуҗа.

Сыерларны саварга укытучы булып эшләүче хатыны Елена, өч баласы, аеруча олы улы Виктор булыша.

– Иң мөһиме – сәламәтлек кирәк. Калганы тырышлык белән дә була. Киләчәктә сыерлар санын 100гә җиткерергә исәп, – ди Сергей.


Гаилә фермасын булдырган Сергей Рыжков

Зөлфия Хәлиуллина фотолары

ЧҮП – ЧҮП МӘСЬӘЛӘ

АКТУАЛЬ ТЕМА

Чүптән дә күп нәрсә юк хәзер. Шәһәрләр генә түгел, авыллар өчен дә актуаль проблема булып тора ул. Дөрес, кайбер районнарда чүп җыю мәсьәләсе хәл ителгән. Атналар буе җыелган чүпләрен капчыкларга тутырып, капка төпләренә чыгарып куялар да махсус тракторлар аларны районның төп полигонына алып китә. Авыл халкы аның өчен акчаны ай саен махсус тариф буенча түләп бара.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының матбугат үзәге хәбәр итүенчә, Татарстанда 53 муниципаль полигон исәпләнә. Чүпне эшкәртеп, аерып җыя торган полигоннар исә бишәү генә: аның икесе – Казанда, тагын икесе Чаллыда урнашкан, берсе Кама Аланында эшли.

АВЫЛЛАР ЧИСТАРДЫ

Кама Тамагы районының күп кенә авылларында мондый «цивилизация» булмаса да, Олы Карамалы авылында ул 2009 елда ук хәл ителгән. Авыл җирлеге башлыгы Эдуард Байдамшин сөйләгәнчә, чүпне районнан килеп алып китәләр. Кыш көне ике айга – бер, җәй көне айга ике тапкыр булырга мөмкин. Чүп күбрәк җыелганда ешрак та.

– Халыкка алдан ук хәбәр бирәбез. Алар билгеле бер көнне чүпләрен капчыкларга тутырып чыгарып куялар. Алардан моның өчен акча җыелмый. Бу максатларга үзара салым акчасын тотабыз. Елына 30-40 мең сумга төшә. Авылда чүп полигоны тотканчы, аны озату яхшырак. Элек авылда чүп күп иде, хәзер чистарды. Баштарак контейнерлар да куеп карадык. Әмма анда төзелеш материалларын да, бакча чүпләрен дә чыгарып ташлый башлагач, ярты көндә ул тула иде. Бу ысул уңышлы булып чыкмады. Авыл уртасында чүп җыелып тормасын, дидек. Авыл халкы үзе дә бу эшкә җаваплы карарга тиеш. Капка төбендә, бакча буйларында чүп җыеп яткан кешеләр белән сөйләшүләр алып бардык. Нәтиҗәсе булды – тәртәгә керделәр дияргә була. 2020 елга Казанда чүп яндыру заводы төзеләчәк, диләр. Районнарда җыелган чүпне пресслап, шунда озату җае әйбәт булыр иде, – ди ул.

Ә менә шул ук районның Балтач авылында авыл халкы чүпне махсус контейнерларга чыгара һәм алар тулгач, авыл башындагы вакытлыча эшли торган чүп полигонына озаталар. Моның өчен халыктан акча җыелмый. Әмма чүпне кая куярга белмәгәндә, аны полигонга төяп барырга махсус техникаң булмаганда, бу ысул да ярап куя.

Яшел Үзән районының Олы Яке авыл җирлеге башлыгы Фирая Фәйзуллина сөйләвенчә, авыл җирендә чүп елдан-ел арта бара. Чүпне атнага ике тапкыр җыеп алып китәләр.

– Авылның алты урынында контейнерлар куйдык. Халык чүпне шунда чыгарып сала. Бу эш өчен ай саен кеше башына 44 сум түлисе. Дачниклар сезон өчен генә түли, алардан сезонына 600 сум җыю каралган. Исәп-хисап суммасы су квитанциясенә язылып килә. Суны чишмәдән алучылар өчен оешманың үзеннән чек алып кайтабыз. Чүпне «Мега плюс» компаниясе техникасы килеп алып китә дә Әйшә авылындагы полигонга илтеп тапшыра. Белүемчә, анда чүпне сортларга аералар. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү белән «Экоресурс» компаниясе шөгыльләнә. Баштарак авыл халкының чүп җыйган өчен акча түлиселәре килмәде, минем чүбем юк, дип кенә әйтәләр иде, хәзер ияләштеләр инде. Авыл да чистарды. Контейнерлар торган урынны махсус бер кеше җыештыра. Бу эшкә авыл кешеләре үзләре дә теләп алына, – дип сөйләде ул безгә.

ЧҮП ПРОБЛЕМАСЫ ХӘЛ ИТЕЛӘЧӘК

Аксубай районында исә халыкның чүбен җыеп, үзәк полигонга илтеп бушату эше әлегә хәл ителмәгән. Әмма Аксубай районы башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Илдар Ислямов сүзләренчә, якын киләчәктә ул хәл ителәчәк.

– Чүп-чар әйләнеше өчен җавап бирәчәк төбәк операторлары барлыкка киләчәк. Шуннан соң бу эш җайланыр дип уйлыйбыз. Әлегә авыллар үзләренең чүбен махсус чүп базына илтеп түгә. Аны карап, тирәсен җыештырып тору – авыл җирлекләре карамагында. Капка төпләрендәге, бакча буйларындагы чүп өчен авыл халкына кисәтү ясыйбыз, штраф түләттерәбез, – диде ул.

Илдар Ислямов әйтеп киткән төбәк операторлары, Россиядә беренчеләрдән булып, Татарстанда эшли башлар дип көтелә. Татар районара табигатьне саклау прокуроры Илсур Гыйльметдинов «ШК»га сөйләгәнчә, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» федераль законга үзгәрешләр кертелгән. Бу мәсьәлә уңаеннан республикада чүп калдыклары белән эш итү буенча территориаль схема эшләнеп кабул ителгән. Нәтиҗәдә ике чүп зонасы барлыкка киләчәк: Көнбатыш һәм Көнчыгыш. Көнбатыш зонага – 21, Көнчыгыш зонага 22 муниципаль район керә. Бу ике зона өчен ике төбәк операторы җавап бирәчәк.

– Алар полигоннар, чүп җыю, утильләштерү, сортларга аеру, транспорт өчен җавап бирәчәк. Берәр җирдә чүп өеме барлыкка килсә дә, алар җавап тотачак. Кем гаепле дип эзләп йөрисе булмаячак. Барысы өчен дә шушы ике оператор җавап бирәчәк. Алар тарафыннан экологик технопарклар булдыру да каралган. Моның өчен бюджеттан акча бүленмәячәк. Төбәк операторлары полигоннар төзү буенча үзенең инвестицион проектын тәкъдим итәргә тиеш. Аларны конкурс буенча сайлап алачаклар. Быелдан эшләп тә китәрләр дип уйлыйбыз. Шушы мәсьәлә хәл ителгәннән соң республика буенча чүп проблемасы уңай якка үзгәрер дип өметләнәбез, – диде ул.

Аның әйтүенчә, халыктан чүп җыйган өчен алына торган сумма күпкә артырга тиеш түгел. Төбәк операторларының узган елның сентябрь азагында расланган яңа территориаль схемасы буенча эшен Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы алып барачак. Күп фатирлы торак йортларның идарәче компанияләре дә, шәхси йорт хуҗалыклары да, бакчачылык ширкәтләре дә төбәк операторы белән килешү төзеп, хезмәт өчен түләргә тиеш булачак.

ТӨЗЕЛЕШ КАЛДЫКЛАРЫН КАЯ КУЯРГА?

Авыл халкын борчыган тагын бер мәсьәлә – төзелеш калдыклары, кисеп ташланган агач-куак ботаклары. Аларны каты көнкүреш калдыклары белән бергә алып китмиләр. Элек мондый төр чүпне яндыралар иде, хәзер яндырырга да ярамый, төтенне күргә ук килеп, штраф салып китәләр. Бердәнбер юл – чүп базына ташлау. Әмма авылларда аларны күмеп куярга җыеналар. Балтач районы Чепья авылы җирлеге башлыгы

1 апрельдән Татарстанда санитар-экологик икеайлыкка старт бирелгән иде. Шул вакыттан бүгенге көнгә кадәр республика территориясендә 1,2 мең законсыз чүплек табылган, аларның яртысыннан артыгы юк ителгән. Муниципаль берәмлекләрдә 152,5 млн кубометр каты көнкүреш калдыгы чыгарылган. Территорияне чистартуга 700 меңнән артык кеше һәм 4 меңгә якын махсус техника җәлеп ителгән.

ТҮГЕЛ

Минсагыйт Шакиров, Татарстан Муниципаль берәмлекләр советы рәисе:

– 131нче Федераль закон буенча шәһәр бистәләре, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары вәкаләтенә чүпне җыю һәм җирлектән чыгарудан тыш, сортларга аеру, утильләштерү, күмү эшләрен оештыруда катнашу керә. 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45нче законда җирле үзидарә органнары көнкүреш каты калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю) һәм аны ташуны оештыруда хезмәттәшлек итә диелгән. Җирлек башлыкларының вазифалары менә шуннан гыйбарәт. Чүп җыю һәм аны ташу буенча җаваплы дигән сүз юк анда. Авыл җирлегенә бу эш өчен аерым акча да бүлеп бирелми. Халыктан җыелган акчага хәл ителә бу мәсьәлә. Элек халык чүпне авыл башында файдалы казылма байлыкларыннан бушап калган яки башка бер чокырга илтеп ташлый иде. Аның легаль чүплекме-юкмы икәнен тикшерүче дә булмады. Бернинди штраф та түләттермиләр иде. Хәзер, бердән, чүпнең күләме артты, элеккеге кебек, кибеткә сетка белән йөрүчеләр бетте, пакетлар кулланабыз. Анвары кибет киштәләрендә монын кадәр продукт та юк иде. Берсеннән-берсе ялтыравык, матур төргәкләрне күргән дә юк иде. Алар белән бөтен чүп контейнерлары тулган. Икенчедән, экологиягә дә игътибар артты.

Каты көнкүреш калдыкларын аерып җыю чит илләрдә файдалы бизнес санала. Узган ел Австриядә, аннан алдагы елда Италиядә булдык. Аларда чүпне яндырганда бүленеп чыккан электр энергиясен куллану практикасы бар. Чүп каян җыелган, электр энергиясен шул җирлек халкы куллана. Бездә бу нәрсә керә генә башлады.

Безнең авылларга килгәндә, ел саен 104 авыл җирлегенә грант – бер миллион сум акча бирелә. Кайбер авыллар бу акчага трактор сатып алды. Шуның белән чүп җыю һәм ташу мәсьәләсен берникадәр хәл ителәр. Киләчәктә исә бу эш белән төбәк операторлары шөгыльләнәчәк. Чүп проблемасын хәл итүнең бу – бердәнбер максатчан юлы. Авылларда чүплекләр тулды, яңаны казый алмыйбыз. Буш җирләр юк, кырларда иген үстерәсе бар.

Азат Нотфуллинны да борчый бу мәсьәлә.

– Каты көнкүреш калдыкларын җыю эше җайга салынды. Ә менә төзелеш калдыкларын, бакчадан чыгарылган чүпне авыл башындагы чүп базына илтеп түгәбез. Кайбер авылларда мондый вакытлыча полигоннар ябыла башлаган дип ишеттем. Ә аларны кая куярга соң? Кабат елга-күл, урман буйлары чүп белән тулырмы икән инде? – ди ул.

Сөйләшүебез барышында ул әлеге уңайдан яңа проект артыннан йөрүен дә әйтте.

– Унбер авылга бер чүп полигоны эшләргә уйлыйбыз. Анда чүп җыелып кына калмыйча, сортларга да аерылачак. Полигон Чепьядан Балтачка таба баргандагы юл өстендә булачак, 8 гектар җирне биләячәк. Бу эш белән 2012 елдан бирле йөрибез, законнар да гел үзгәреп тора. Хәзер менә проектны экологик экспертиза аша уздырасы бар, – дип планнары белән уртаклашты Азат Нотфуллин.

ЗАКОНСЫЗ ЧҮПЛЕКЛӘР

Россия авыл хуҗалыгын күзәтү үзәгенең Татарстан буенча идарәсенең Җир контроле бүлеге авыл хуҗалыгы җирләренең тиешле максатларда кулланылуын күзәтү астында тота. Әлеге җирләрдә легаль булмаган чүплекләргә дә тап була алар. Бүлек җитәкчесе Артур Зәкиев сүзләренчә, узган елны гомуми мәйданы 67 гектарны тәшкил иткән 99 чүплек табылган.

– Статистика буенча, иң күп законсыз чүплекләр Мамадыш, Кукмара, Лаеш, Югары Ослан районнарында табылды. Быел әле кырларга чыккан юк, җирләр кипмәгән. Гадәттә, безнең тарафтан табылган чүплекләр юк ителә, чистартыла. Бу бик актуаль проблема. Күп кенә районнарда чүп җыю эше җайга салынмаган. Моңа авыл җирлекләре башлыклары һәм халык үзе дә игътибарлы булырга тиеш. Чүпне алып китү, юк итү белән шөгыльләнүче компанияләр шактый. Алар белән килешү төзү һәр як өчен дә уңайлы, – дип сөйләде ул.

- 2016 елда Татарстанда каты көнкүреш калдыкларының күләме 1 миллион 573 мең тоннага җиткән. 2010 елдан аның күләме якынча 370 мең тоннага арткан.
- Бүгенге көндә бөтен республикада чүпне аерым җыю өчен 200гә якын контейнер, пластик шешәләр җыю өчен берничә йөз контейнер һәм терекөмешле лампа һәм батарея кебек куркыныч каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен 100гә якын контейнер исәпләнә.
- Республикада зур предприятиеләрдән чүп-чар җыю белән шөгыльләнүче унга якын эре компания бар.
- Татарстанда ел саен 10 млн тоннага якын чүп-чар калдыгы җыела, аларның 60 проценты — терлекчелек, 28 проценты — сәнәгать һәм 12 проценты — көнкүреш каты калдыклар.
- Россия буенча чүп-чар елына 30 млрд тоннадан артык җыела.
- Россиядә чүплекләр 48 мең гектарны алып тора.
- Көнкүреш каты калдыкларының 8 проценты гына утильләштерелә.
- Ел саен каты көнкүреш калдыкларыннан 1,5 миллион тонна корыч, 100 мең тоннадан артык алюминий, 2 мең тоннадан артык аккургаш, 10 миллион тонна макулатура һәм 2 миллион тонна пластмасса алып булыр иде.
- Европада кәгазьне дүрт-биш тапкыр кулланалар.

Булмас димә...

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

Аңлап та, аңлатып та булмый торган нәрсәләр бар бу дөньяда. Менә өч кенә мисал...

Төш күрдем берсендә. Авылда берьюлы өч кешене күмәбез икән дим. Урам тулы халык, барысы да ир-атлар, барысы да карадан киенгән, ак кәфенлеккә төрелгән өч мәетне күтәреп, зиратка таба баралар. Бу өчәүнең берсе – безнең каршыда торган Рәвис абзый, ул чыннан да күптән түгел вафат булган иде. Мин боларга карап уйлап торам: «Ярар, – мин әйтәм, – Рәвис абзый үлде инде, ә теге икесен ник зиратка алып баралар соң? Алар исән бит әле».

Ә иң гаҗәпләндергәне шул: төштә бу икәүнең кемнәр икәнен белә идем, ә уянып киттем – хәтерләмим. Искә төшерергә тырышып күпме генә утырсам да, барып чыкмады. Озак та үтмәде... әтинең абыйсы һәм әнинең сеңлесе бербер артлы үлеп киттеләр.

Теге дөньяга китеп барган кешенең җаны 40 көн буена туганнары арасында йөри дигән ышану бар бит. Теләмәгән җиреңнән ышанырсың! Бертуган сеңлем юл һәлакәтендә вафат булганнан соң авылдагы йортыбызга бер күгәрчен ияләште. Гади генә күгәрчен түгел иде ул, аңа карагач, бу патшабикәдер инде дип уйлап куярлык иде. Үзе ап-ак, башында кечкенә генә бик матур бүреге бар, ул күбрәк таҗны хәтерләтә иде. Койрыгы бик озын, тавис кошыныкы кебек ачылып тора иде. Аяклары күренми иде ул күгәрченнең, алар бик матур йон белән капланган иде.

Менә каян килеп чыккан ул күгәрчен авылда? Бездә генә түгел, якын-тирәдә дә декоратив күгәрченнәрне үрчетүче юк. Нигә ул гел безнең йорт тирәсендә генә очып йөрде? Ник сарай түбәсенә кунып, ишегалдындагы кешеләрне күзәтеп утырды? Һәм иң гаҗәпләндергәне: сеңлемнең кырыгын уздыргач, кая югалды ул?..

Аңлап булмаслык тагын бер хәлне якын туганым сөйләгән иде. Яшь чакта каядыр барышлый, Казан аркылы үткән бу. Анда аның энесе Фәһим укыган булган, аның хәлен белергә дип тулай торакка килгән. Бүлмәдә бер егет утыра икән. «Фәһим эш белән китте, тиздән кайтыр инде», – дигән бу. Энесенең кайтканын көткәндә, аның караватында «Фаэты» исемле китап тапкан туганым, укый башлаган. Фантастик роман булып чыккан бу, Фаэты дигән планетаның һәлак булуы, андагы кешеләрнең башка планеталарга таралуы турында. Бик мавыгып укыган китапны туганым, сәгать артыннан сәгать үтә торган, ә Фәһим кайтмый да кайтмый икән.

Китәр вакыт җиткән. Тик романны укып бетерәсе килә бит инде моның хәзер! «Алып торыйм әле бу китапны, бер атнадан тагын Казанга киләсем бар, шунда кайтарырмын», – ди икән туганым Фәһимнең бүлмәдәшенә. «Юк, ярамый, – дигән егет. – Аны башка кешеләр дә сорап караганнар иде, Фәһим беркемгә дә бирмәде, китапханәгә илтәсем бар, ачуланалар, диде. Киткәндә кат-кат әйтте, китапны сорасалар, беркемгә дә бирмәскә кушты», – дип аңлаткан студент.

Туганымның шулкадәр укып бетерәсе килгән бу китапны! «Әй, ярар ла, бер атна соңрак тапшырганга китапханәдә атып үтермәсләр әле», – дигән дә бу, теге егет күрмәгәндә генә китапны алып китеп барган.

«Өч көннән Фәһим үлде, дигән хәбәр килде, – дип сөйләде туганым. – Казаннан алып кайтып күмдек. Өчесен, җидесен уздырдык. Бөтен сөйләшү гел Фәһим турында, һәрберсе аның белән бәйле төрле хәлләрне искә төшерә. Берничә кеше Фәһим төшемә керде, фәлән дип әйтте, төгән итте дип сөйләшәләр. Шунда Фәиз, ун яшьлек малай, әйтеп куймасынмы:

– Фәһим абый минем дә төшкә керде! «Китабымны урладылар», — диде. Исемен дә әйткән иде, хәзер әйтә белмим инде. Ат арбасының исеменә охшаган, тик «Карета» да түгел, «Экипаж» да түгел, башка төрле исем, «ф» хәрефенә башланган бугай...

– «Фаэты»мы? – дидем, аптырап.

– Әйе, әйе, «Фаэты»! – дип шатланды Фәиз. – Фаетон дигәнгә охшаган дип уйлаган идем...

Менә ничек итеп ул балага андый төш керә ала? Мин бит Казанда чакта тулай торакка барганымны да, Фәһимнең китабын алып киткәнемне дә беркемгә дә әйтмәдем», – дип исе китеп сөйләгән иде туганым...

Бу хәлләрне азмы-күпме аңлар өчен шуны гына әйтеп була, кеше бит ул күнегүчән. Бөтен нәрсәгә дә күнегә кеше – матурлыкка, кабахәтлеккә, тәрбиясезлеккә күнегә, чөнки бу әйберләр аны әйләндереп алган һәм көн саен шул. Әгәр көн саен кем дә булса каһарманлык кыла башласа, кешеләр моңа да күнегәчәк, шулай булырга тиеш итеп кабул итәчәкләр. Вак мәшәкатьләр — кемгәдер шылтыратырга кирәк, каядыр барырга кирәк, ниндидер пүчтәк максатка ирешергә, нәрсәдер сатып алырга, кемнедер җүләр калдырырга, икенчесеннән үч алырга һәм башкалар, һәм башкалар — безгә боларның барысы да бик мөһим булып тоела! Чынлыкта алар өч тиенгә дә кирәкми! Чөнки вак мәшәкатьләр белән узган тормыш — буш тормыш, истә калырлык берни дә юк анда.

Ә нинди вакыйгалар истә кала? Безнең яшәешебезнең тизлеге, ритмы үзгәргән мизгелләр: гашыйк булу, чын сәнгать белән очрашу, якыныңны югалту. Андый чакларда кеше дөнья ыгы-зыгысыннан арына, бертуктаусыз чабудан туктап як-ягына карана, уйлана башлый. Хәтта иң каты бәгырьле кеше дә, озакка түгел, беркадәр вакытка гына булса да йомшара, күңеле яхшылык белән тула.

...Бик якын кешеңне югалтудан да көчлерәк шок була алмыйдыр ул. Күрәсең, андый чакларда кеше миенең активлыгы арта, гадәти тормышта кулланылмаган, кирәк булмаган мөмкинлекләре эшкә җигелә башлый.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

Бу язылу кампаниясендә укучыларыбызны нинди бүләк белән сөендерик икән, дип озак уйландык. Үзе файдалы да, истәлекле дә, матур да булсын иде ул бүләк. Уйлый торгач таптык тагын: без сезгә, Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигы белән берлектә, алмагач үсентеләре бүләк итәбез!

Бүләк алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм жирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатыла. Жирәбә уйнатуны видеога төшереп, **www.shahrikazan.com** сайтында урнаштырачакбыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР
П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон________________
____

2. Яшегез________________________________

3. Шөгылегез______________________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?______________________________
____

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?_____________________________
____
____

6. Газетага ничек язылсасыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?
____

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?
____
____

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?______________________________
____
____
____
____

10. Газетаның миңа иң ошаган:____________________
____
____

ошамаган яклары:________________________________
____
____

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?
____
____
____
____

Языл → **Анкетаны тутыр** → **Җибәр**

«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша языл

Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:
Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе
Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com
Ватсап: 8 917-851-69-62
Социаль челтәрләрдәге төркемнәр:
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
ok.ru/shrikazan

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан берәр җайланма булуы гына кирәк

1. uslugi.tatarstan.ru сайтына кер;
2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;
3. Шәхси кабинетыңа кер;
4. «Шәһри Казан» (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;
5. Адресыңны яз;
6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

АШ БУЛСЫН

Венера Мәҗитовадан шәфталулар

Иң элек шәфталуларның камырын эшлибез. Моның өчен башта ике йомырканы туглыйбыз, шуннан соң аңа 180 грамм шикәр комы кушабыз. Шикәр комы эреп беткәнче туглагач, бер чеметем ванилин, бер чеметем лимон кислотасы, 1,5 аш кашыгы 20 процентлы кибет каймагы, 60 грамм өй температурасында йомшарган ак май салып, тагын туглыйбыз. 500 грамм он һәм 1 чәй кашыгы камыр йомшарткыч (разрыхлитель) салып, камыр басабыз. Камырны бер сәгатькә суыткычка куябыз. Аннары камырны икегә, һәр кисәген тагын 10-12 кисәккә бүләбез. Шул кисәкләрдән шарчыклар әвәлибез. Әстерхан чикләвеген икегә аерабыз, эчен алабыз. Шарчыклардан чикләвекләр өстенә «эшләпә»ләр ясап кидерәбез. Шарчыкларны пергамент кәгазе өстенә куеп, духовкага озатабыз. Йөзләре алсулана башлауга, духовкадан алабыз. Шарчыклар эченә тутырырга әчлек эшлибез. Аның өчен кайнатылган сөт (вареная сгущенка), йомшарган ак май, чикләвекне алганда ватылган камыр кисәкләрен кулланабыз. Әчлекне шарчыклар эченә тутырабыз. Һәркайсына әстерхан чикләвеге төшләре куеп чыгабыз. Ике шарчыкны бер-берсенә тоташтырып, 1 сәгатькә суыткычка куябыз. Шикәр комын буяр өчен, кишер һәм чөгендерне сыгып, сутлар әзерлибез. Шарчыкларны суыткычтан алып, бер ягын – кишер, икенче ягын чөгендер сутына чумдырып алабыз. Аннары шәфталуларны буялган шикәр комында әвәләп алабыз. Кишер төсендәге шикәр комында – бер, чөгендернекендә – икенче ягын. Тәмле шәфталулар әзер. Хәзер алар белән тәмләп чәй эчәргә дә була.

БАКЧАЧЫГА

Гладиолусларны кайчан утыртырга?

Гладиолусларны 10-12 см тирәнлектәге җир +8 +10 градуска кадәр җылынгач утыртырга кирәк. Күп кенә бакчачылар аларны кышка саклаrга куйганда, янәшәсенә сарымсак куеп калдыра икән. Болай итәргә өлгермәгән булсагыз борчылмагыз. Ул утыртыласы җиргә сарымсак төнәтмәсе (10 литр суга 40-50 гр изелгән сарымсак; бер тәүлек төнәтеп сөзеп аласыз) сибегез. Алай ирендерсә, гладиолус янына сарымсак утыртыгыз. Гладиолуслар янәшәсенә бәрхет чәчәге, настурция һәм календула да утыртыгыз. Утыртыр алдыннан бер-ике сәгать марганцовка эремәсендә тотыгыз. Бүлбеләре зуррак булган саен, тирәнрәк утыртыгыз.

Гладиолуслар күзне гел иркәләп чәчәк атып утырсын дисәгез, аларны 10-12 көн аралыгы белән төрле срокта утыртыгыз.

Помидорны трихопол белән «сыйлагыз»

Помидорларны фитофтороз авыруыннан саклау өчен, трихопол кулланыгыз. 20 дару төймәсен ун литр суда эретеп, ун көнгә бер тапкыр шуны сибегез. Икенче көнгә яңгыр яуса, кабат эшкәртегез.

Бу очракта сарымсак та ярдәмгә килә. Угычта уылган 50 гр сарымсакка бер литр кефир һәм ун литр су салып бераз төнәтәбез дә помидорга сибәбез.

ХУҖАБИКӘГӘ

Өй җыештырганда музыка тыңлагыз

ӨЙ ҖЫЕШТЫРУНЫ ТИЗЛӘТҮ ӨЧЕН ТҮБӘНДӘГЕ КИҢӘШЛӘРНЕ ИСТӘ ТОТЫГЫЗ:

- *Бу эшне иң ерак бүлмәдән башлагыз, иң соңыннан бәдрәф һәм ванна бүлмәсен юыгыз.*
- *Тәрәзәләр «тирләмәсен» өчен аны глицерин белән сөртегез.*
- *Көзгене чи суган белән чистартсаң, аңа чебеннәр кунмаячак.*
- *Раковинада су тыгылмасын өчен вакыт-вакыт аңа ике-өч литр кайнар су агызыгыз. Ул торба эченә утырган майны эретә.*
- *Газ плитәсен ашарга пешергәч үк сөртеп алырга гадәтләнегез.*
- *Лакланган һәм полировкаланган мебельне коры чиста чүпрәк белән сөртегез. Иң яхшысы – фланель.*
- *Линолеум җәелгән идәнне кайнар су һәм составында сода булган порошок белән юарга кирәкми.*
- *Паркетны юарга кирәкми, дымлы чүпрәк белән сөртеп кенә алыгыз.*
- *Суыткычта ят исне активлаштырылган күмер бетерә.*
- *Ванна белән раковинаны бер-бер артлы кайнар һәм салкын су белән юмагыз – эмаль ярылырга мөмкин.*
- *Хрусталь савыт-сабаны кайнар су белән юмагыз.*
- *Тәрәзә юа торган суга бераз гына марганцовка салыгыз, пыяласы ялтырап китәр.*
- *Өй җыештырганда музыка тыңлагыз, вакыт та тиз уза, кәеф тә күтәренке була.*

ТӘМЛЕ

Май бәйрәмнәрендә безнең халыкта шашлык кыздыру традициясе бар. Шашлык тәмле булсын өчен, кайбер киңәшләребезне истә тотыгыз.

Иткә тоз белән борыч кына сибеп кыздырсаң да тәмле була, әмма тәмләткечләр дә сибәсе килгән кешегә киңәш: бәрән итенә изелгән кара бөрлегән сыласаң һәм бөтнек сипсәң яхшы була. Тавык итенә маринад өчен катык яки кефир сайлагыз.

Мангал өчен иң яхшы утын – виноград чыбыгы. Ул тиз яна. Ылыслы агачлар һәм усак утыныннан иттән әче тәм киләчәк.

Иттән күмергә кадәр ара якынча дүрт бармак булырга тиеш.

Шампурга ит арасына суган куеп кыздыру дөрес түгел. Суган тиз яна.

Күмер янып китә башласа, су урынына тоз сип.

Шампурны рәшәткә өстенә куяр алдыннан күмер өстенә бернечә ботак бәбрия (розмарин), тархун, шалфей ыргытыгыз – итегез хуш исле булыр.

Шашлыкны кетчуп, майонез белән ашамыйлар.

АЛТЫН СҮЗЛӘР

Баш миенә тискәре тәэсир итүче күренешләр

Йокы туймау. Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы мәгълүматларына караганда, соңгы йөз елда кеше уртача 20 процентка азрак йоклый башлаган. Йокы туймаудан баш мие кузәнәкләре үлә башларга мөмкин.

Иртәнге ашны ашамау. Моныысы исә эшкә сәләтлелекне киметә. Иртән ашамагач, кандагы шикәр күләме кими. Бу, үз чиратында, баш миенә туклыклы матдәләрнең килүен акрынайта.

Баллы ашау. Шикәр күп булу аркасында аксым начар үзләштерелә.

Стресс. Стресслар хәтернең начараюына китерә, интеллектуаль потенциалны киметә.

Йоклата торган дарулар һәм депрессиягә каршы препаратлар. Алар шулай ук хәтерне боза.

Тәмәке тарту. Никотин кан тамырларын кыса. Альцгеймер авыруы барлыкка килү куркынычын арттыра.

Кояш нурлары җитмәү. Ультрашәмәхә нурлар кан әйләнешен, ягъни кислород һәм туклыклы матдәләр килүне көйли. Шулай ук ул кешенең кәефенә тәэсир итә торган серотонин гормонын барлыкка китерергә ярдәм итә. Без һәр көн биш минут булса да саф һавада йөрергә тиеш.

Су. Су җитмәү баш мие күләме кимүгә китерә. Шуның белән эшкә сәләтлелеген киметә.

Мәгълүмат күп булу. Бу, бер караганда, баш мие өчен күнекмә генә кебек. Әмма ул күп булганда, кеше аны «үзләштерергә» өлгерми.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Кыяр үстерү сере

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

АЛАР БЕЗГӘ ҖИҢҮ КИТЕРДЕ

«Сугышка алганда, биография сорамадылар»

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Аны сугышка 17 яшендә алалар.

– Сугышка киттем дип сөйләсәм, дөрес булмас. Алдылар дип әйтим, – дип искә ала 1943 елның июнь иртәсен Балтач районы Түбән Кенә авылында яшәүче Тәскирә Галимуллина. – Хәзер уйлыйм, авыл советына нәрәт килгәндер дә иң беренче чиратта безнең гаилә торгандыр. Кагылулы булдык шул без. Әтиебез колхоз председателе иде, аны сугыш башланганчы кулга алдылар. Без, аннан халык дошманы ясаганнар, дип тә белмәдек. Бик яшь идек шул әле... Югыйсә мин укытучы булырга хыялланган идем. Җиденче классны тәмамлагач, сыйныф җитәкчем Арча педучилищесына алып барган иде. Биографиясе туры килми дип алмадылар. Укытучым миңа ул вакытта барысын тәфсилләп аңлатып тормады. Бер әнигә дүрт бала, акча да түлисе бар, тарта алмаслар дип әйттеләр генә диде. Анысын да соңыннан белдем, әтинең кулга алынуы сәбәп булган. 17 яшемдә шинель кидертеп сугышка алып киткәндә, биография кирәк булмады...

1943 елның июненнән 1944 елның гыйнварына хәтле Казанда элемтәче булырга әзерлиләр аларны. 40нчы завод ишегалдында землянкалар казып шунда торалар. Иделдән агып килгән саллардан агач бушатырга да йөриләр. Шушында ук аларга карабиннар биреп атарга да өйрәтәләр.

– Барлык халык өчен дә бик авыр еллар... Базарда бер буханка ипи 300 сум тора, анысы да әле юк. Бик начар гына булса да, безне ашаталар, көн саен бер телем сохари бирәләр. Без аны кәбестә шулпасында җебетеп ашыйбыз. Үз гомеремдә нинди генә ризыклар ашамадым, әмма әнә шул сохариның тәмлелеге әле дә исемдә. Ач идек шул. Кайчакта уйлыйм, бүгенге муллыкның, ризыкларның кадерен белеп, бәяләп бетермиләр кебек.

Иң беренче бомбежкага юлда ук эләгәләр алар, иң беренче югалтуны да шунда кичерәләр: иптәш кызлары үлә. Уңайсызланып булса да, беренче кичерешләрен, чыпчын сугышка иң беренче тапкыр килеп керүләре турында сорыйм Тәскирә ападан.

– Әй, кызым... Сугыш турында күпме кинолар төшерелгән, нинди генә китаплар юк, ләкин аларның берсе дә чын сугыш йөзен ачып бирми. Шул китап битләренә безнең йөрәкне кадап куйсаң да, ул да аңлатып бетерә алмас кебек. Сугыш ул – коточкыч, кешелек дөньясы өчен иң зур афәт.

Аларның часте иң элек Украинага урнаша. Землянкалар казып, элемтә линиясен сузып бетермиләр, кабат күченергә кирәк була. Яңадан землянка казыйсы, катушкаларны өстерәп, линия сузасы.

– Постта торганда берүзең генә буласың, шул вакытта бомбежка башланса, белгән догаларымны укый торган идем. Бомба сиңа очып килә кебек, баш очында гына шартлый дигәндә, Аллаһ рәхмәте белән, читкәрәк китеп шартлый. Исән калганыңны аңлагач та, линияләрнең төзеклеген тикшерәсен.

Сорна елгасы аша салынган күперне дә саклыйлар Тәскирә апалар. Германиягә илтә торган бердәнбер тимер юл була бу. Нәкъ менә шунда алар янына концерт белән артистлар килә. Русча җырлардан соң бер артист кыз «Кошлар кебек» дигән җырны татарча башкара. Тәскирә апа, аңа кушылып, Татарстаннан килгән рус кызлары да елый башлыйлар.

– Татарча булса да, рус кызларының да күңелен кузгатты бу җыр, алар да бит шул моңны ишетеп үскәннәр, аларга да ул якын. Җыр бетүгә, җырчы кыз янына барып исемен сорарбыз дигән идек, ул арада бомбежка башланды. Тынычлык урнашканда, артистлар киткән иде инде.

Шул концерттан соң мин әнигә шигъри юллар белән хат яздым:

Әнкәй мине бик сагынсаң,
Кара кояш баешын.
Шул яшь кенә билләремә
Будым солдат каешын...

Җырчы кызны Тәскирә апа сугыш беткәннән соң эзләп таба. Иң элек шул концертта катнашкан биюче кыз Хәдичәне телевизордан күреп танып ала. Казан филармониясендәге очрашудан тапшыру күрсәткән булалар. Аннан соң филармониягә хат язып, Хәдичәне таба һәм аның аша җырчы кыз Зита Исмаилова турында белешә. Сугыш башлангач, ятимә кызны Украинадан Казанга җибәргән булалар, профессиональ җырчы да булмый ул. Бик матур җырлагач, заводта эшләгән җиреннән, артистлар үзләре белән алып чыгып китә. Сугыштан соң ул Ташкентта урнашып кала. 1983 елда Казан филармониясе Зита, Хәдичә, Тәскирә апаларны кабат күрештерә. Аннан соң да күп еллар аралашып торалар. Хәдичә белән Тәскирә апа үзләре азат иткән Украина җирләренә дә берничә тапкыр очрашуларга баралар.

– Җиңүне мин Польшада каршы алдым. Бик матур яклар. Әй андагы алма бакчалары, елга буендагы карлыганнарның өлгереп утырулары – әле дә күз алдымда. Сугыш беткәч, берничә тапкыр Брест шәһәренә алып чыктылар. Киноны да иң беренче тапкыр шунда карадым. Без бит бик тә хәерче тормыштан килгән гап-гади авыл балалары. Нәрсә күргән идек без? Иң беренче кигән рәтле киемебез дә шинель, гимнастерка булды. Без чалбарны постка басканда гына кия идек. Болай һәрвакыт итәктән. Юка һәм калын оеклар бирә торганнар иде. Эчке киемне дә сугышта күрдек һәм кидек. Брестта калыгыз дип бик кыстадылар. Эшкә урнашыгыз, аннан соң туган якларыгызга кайтып килерсез, диделәр – калмадым. Туган туфрак тартты. Кайтсак, андагы хәерчелек... Әти өчен каһәрләү дә һаман дәвам итә. Мине бит пионерга да, комсомолга да алмадылар... Әлбәттә инде, ник кайттым, дип үкендем. Әнием бик акыллы, сабыр хатын иде. «Тормышлар көйләнер. Монда да яшәү рәхәт булыр. Кунакка кайтырсың, нигә чит җирләрдә калдым икән дип йөрәгең әрнер», – дип үгетләде ул мине. Ялгышмаган, менә бүген тормышыбыз ничек матур. Бүгенге көндә Киевны уйлап та борчылам. Сугыштан соң күп тапкырлар хөрмәтләп чакырып кунак иттеләр. Без саклаган күперне дә чуеннан корганнар иде. Нинди шәһәр иде бит. Хәзер телевизордан күрәм, җимереп бетерәләр. Әй ул сугыш...

Яшь солдат йокысы

Вакыт бик тиз уза. Әтиебез Бөек Ватан сугышы ветераны Әнвәр Зариф улы Вафинның арабыздан китүенә дә 20 ел булган. Сугышта үзе белән булган вакыйгаларны ул исе китеп сөйли торган иде.

Кешегә әйтеп кеше ышанмаслык хәлләр, әлбәттә. Әмма булган бит! Әтиемә нибары 19 яшь ул чагында. Өч тапкыр яраланып, 24 яшендә инвалид булып кайта ул сугыштан. Ул сөйләгәннәр бүгенгедәй исемдә.

– Сугышның беренче көннәре иде. Безнең укчылар хәрби часте һаман чигенә дә чигенә. Йөрәккә кан салып, көннән-көн артка чигәбез. Чигенүебез буталчык бер нәрсә. Солдатлар тәмам алҗыган, пычракка бату гына җитмәгән, шуның өстенә ач та. Кайда штаб, кайда санчасть, кайда кыр кухнясы – еш кына аңлап та булмый. Фронт бик тиз күчә, үзгәрә, дошман һаман кыса, кысрыклый бара. Артыбыздан бер тотам калмый, тын алырга да ирек юк. Эчтә үч кайный. Без, бер төркем солдатлар, чираттагы канкойгыч сугыштан соң командирыбыз белән инде көне буе полк штабын эзләп йөрибез. Арыганлык чиктән ашкан, йокы күргән юк, хәтта атларга да көч калмады. Солдатларның аякта көчкә басып торуын күреп, командир 20 минутлык ял бирде. Дошман күрмәслек итеп, кечкенә түгәрәк уйсулыкка урнаштык. Винтовкаларны кочаклап йокымсырый гына башлаган идек, каяндыр дошман килеп чыгып, безне тиз арада урап алды. Чигенергә юл ябык икәнен барыбыз да шунда ук аңладык. Минометтан һәм автоматтан ата-ата, алар әкренләп без урнашкан урынга килә башладылар.

Ә аннан соң нәрсә булганын белмим. Күземне ачсам, тирә-юньдә һәлак булган иптәшләрем ята, дошман да күренми. Башта ни булганын аңламыйча, тиле сыман карап тордым. Аннары гына хәлсезлектән йокыга киткәнемне абайладым. Дошман бөтен оборона тотучыларны юк иткән. Ә мине, баштан-аяк быкырдыкка баткан, яртылаш җиргә күмелгән, бите тырналып беткән солдатны, күрәсең, үлгән дип уйлаганнар. Шунда уң ягымның авыртуын сизеп алдым, башта яраланганмын, ахры, дип уйлаган идем, җәрәхәт булмады. Күрәсең, минем үлгән булуымны тулысынча ачыклау өчен, дошман итек белән кабыргага типкәләгәндер. Күпме йоклаганмындыр, белмим. Караңгылык төшкәч, винтовкамны эләктереп, чаба-чаба көнчыгыш юнәлешенә таба элдертем һәм кояш чыкканда инде үз частемда идем. Кайткач, бу дәһшәтле йокы тарихын политрукка сөйләдем...

Әнвәр Вафин – уңнан икенче.

Монысы Яңа елга берничә көн калгач булды. Таң атканда, дошманга һөҗүм ясарга тиеш идек. Атакага сигнал биреп, күккә кызыл ракета очты. Командирлар, «Алга!» дип, немецларның траншеяларына ташландылар. Без дә, окоплардан чыгып, «Ура!» кычкырып, алар артыннан күтәрелдек. Яр буенда үлгән яшь кенә немецка абынып егылдым. Уң кулының учында, ялтырап, кесә сәгате күренеп тора. Алдым да тагын алга йөгердем.

Сугыш тынды. Тәмәкегә дип кесәгә тыгылсам – теге сәгать. Башка килгән беренче уй – тизрәк аннан котылу иде. Чөнки солдатларда мәеттән әйбер алу гадәте юк иде – аны яхшыга юрамыйлар. Теге солдат күз алдыма килде, ул әйтерсең ташламаска куша иде. Шулай итеп, трофей миндә калды. Сугыштан соң сәгатьне хуҗасының якыннарына истәлек итеп кайтару теләге белән йөрдем. Илчелеккә җибәрер өчен, фотога төшердем, әмма яу кырында һәлак булган, гарип-гораба булып калган тулы бер буын өчен күңелдәге үч, нәфрәт бу адымга барырга юл куймады...

Ринат ВАФИН, Казан.

ЮГАЛТУ

«Кар-бураннарга кереп югалдың, балам…»

Чувашия Республикасына эш сәфәре белән баргач, Комсомол районының Урмай авылына да кереп чыгарга туры килде. Журналист икәнлегебезне белеп алган халык: «Авылыбыз күгендә кара кайгы. Җиде көн элек кенә унынчы сыйныф укучысы Айдарны җирләдек. Авылның күз өстендәге кашы иде егетебез. Мунчада ис тиеп кенә харап булды бит», – дип өзгәләнде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Без барган көнне егетнең җидесен уздырулары да билгеле булды. Мондый зур кайгы кичергән гаиләнең күзенә күренеп, болай да кан сыркыган яраларын кузгатасыбыз килмәсә дә, авыл халкы: «Газетада Айдар турында язылган язмагыз матур истәлек булып калыр иде», – дигәч, егетнең әти-әнисе, туганнары белән очрашырга булдык.

«МЕҢ РӘХМӘТ, УЛЫМ»

Айдар – Гөлнара һәм Динар Хәмдеевләрнең беренче балалары. Февральдә 16 яшен генә тутырган булган егет. Аннан кала тагын ике сеңлесе бар. Айдарны әти-әнисе, якыннары, укытучылары гына түгел, бөтен авыл халкы мактап туя алмый. Чыннан да, ул көнне бөтен кеше Айдар кайгысы белән яши төсле тоелды безгә.

– Айдар бик тәртипле, тәүфыйклы, игелекле, акыллы, мәрхәмәтле, тыйнак, сабыр, кунакчыл, кечене – кече, олыны олы итә белә торган бала иде. Дөньяга килгәндә үк зур гәүдәле, озын буйлы булып туды бит ул. Сыйныфта да ике метрлы озын, мәһабәт буе белән аерылып торды. Әти-әнисенә дә йомшак, ярдәмчел була белде. Ни кушсаң, шуны эшли торган бала иде. Укуында да зур уңышларга гына ирешеп укыды. Аның грамоталары да бер альбом җыелган, – дип, берсен-берсе уздырып, шулкадәр яратып сөйләделәр Айдар турында туганнары.

Киләчәген медицина белән бәйләргә теләгән икән Айдар. Хирург булачакмын, дип хыяллар гына корып калмаган, гел «бишле» билгеләренә генә укыган егет шул максатына таба барган да. Туганнары әйтүенчә, ул хәтта медицина университетының сайтына кереп, биология фәненнән БДИ билетларын да чишеп караган һәм бөтен сорауларга да дөрес җавап биргән булган!

– Ул гел киләчәген уйлады. Вафатына берничә көн кала, әтисенә: «Әти, мин яңа йортта яши алмам инде», – дип әйткән булган. Әтисе аңа: «Улым, ник алай дисең? Синең өчен төзим бит мин аны», – дигән. Айдар: «И әти, тиздән мин укырга китәм, аннан соң практика узачакбыз», – дип әйткән, – дип сөйләде туганнары Зәйтүнә апа.

Гадәттә бик тыныч, сабыр яшүсмер 20се көнне (ул пәнҗешәмбегә каршы төндә үлгән) бик шат күңелле булган, сыйныфташ кызлары белән уйнап-шаярган.

– Айдар мәктәптәге кызларны төрле мәзәк хәлләр сөйләп көлдергән, дип әйттеләр иптәшләре. Фаҗига буласы көнне бервакытта да булмаганча кояш яктысы кебек ачык, шат күңелле иде, диләр, – дип хәтердә яңарта ул көннәрне туганнары.

Мәрхүмнең якыннары сүзләре буенча, Хәмдеевләр яңа йорт җиткерәләр икән. Башка көннәрдә мәктәптән кайту белән үк әтисе янына булышырга дип, шунда бара торган булган Айдар. Әмма ул көнне әтисе килеп йөрмәскә кушкан. Айдар өенә кайткан да, соң гына, сәгать дүртләр тирәсендә мунча ягып җибәргән. Күрәчәктер инде, югыйсә атна уртасында мунча ягу гадәте дә булмаган гаиләнең. Аннан соң ул өлгергәч, яшүсмер бер кат юынып чыккан да әтисеннән чәчен алуын сораган. Әтисе чәчен алгач, көлешеп-шаярышып та алганнар әле. Улының: «Әти, матур булдымы?» – дигән соравына, Динар абый яратып, шаяртып: «И-и-и, улым, бөтен кызлар синеке булыр инде моннан соң», – дигән. Шуннан, мунчага дип чыгып киткән җиреннән, Айдар кире кабат өйгә кереп, әнисенә: «Әни, чәчемне кара әле. Матур алганмы әти?» – дип сораган. Шушы минутларда әти белән әни газиз балаларын исән килеш соңгы тапкыр күрә дип кем уйлаган? Әйтерсең Айдар якыннарына, үзе дә сизмичә-белмичә: «Мине менә шулай матур килеш күңелегездә саклагыз», – дип әйткән кебек…

– Монда да язмыш дими, ни дисең. Башка вакытта чәчен алдыргач, муен-җилкәләренә коелган чәч бөртекләрен өйдә генә юып төшерә иде, бу юлы мунчада коенып чыгарга булган. Югыйсә, улы мунчага барганчы, әнисе шунда озак кына галошлар, итекләр юган әле. Аңа берни дә

булмаган. Үзеннән соң берәү дә мунчага кермәячәген белгәч, Айдар, мичнең эшермәсен ябып юынган инде. Шуннан ис тиеп изрәгән сабыем… – дип өзгәлә Зәйтүнә апа.

– Ул мунчага киткәндә, мин кечерәк ызбада вак-төяк эшләр белән маташып калдым. Эшләремне бетергәч, өйгә кердем. Ул вакытта Айдар кайтмаган иде әле. Шуннан соң тавык абзарының утын сүндереп кердем дә, ятуга ук, йокыга талганмын. Югыйсә, беркайчан да 10да ятып йоклаганыбыз юк иде. Әниләре дә, балалар да төнге 12сез ятмыйлар иде. Ул көнне барыбыз да иртә ятып йоклаганбыз. Эх, абзардан керүгә үк мунчага барган булсамчы, йоклап китмәгән булсамчы… – дип өзгәләнә кайгыдан бетерешкән әти кеше.

Кызганыч, эх, болай эшләсәм, тегеләй итсәм иде, дип өзгәләнүдән берни дә үзгәрми шул. Бәндә тәкъдирдән уза алмый.

Иртәнге дүртенче яртыда йокыдан уяну белән үк, гаилә башлыгы тәрәзәдән мунча утының янып торуын күреп ала. Шуннан соң тиз генә баласының караватын килеп карый. Ул юк!

– Аның урынында булмавын күрү белән, йөрәгем кысылды. Әнисе белән бергә мунчага йөгергәндә дә эчемнән: «Балам исән генә булса ярар иде», – дип теләдем. Юк шул инде… Мунча эчендә аркылы сузылып яткан гәүдәсенә генә тап булдык… Йөрәгем өзелеп төште… Ясалма сулыш та ясадык, әмма соң иде инде…

Без улыбыздан бер каршы сүз дә ишетмәдек. Соңгы көнне дә терлек асларын караганда: «Әти, син ял ит инде. Үзем карыйм», – диде. Мәктәптән кайтып керер иде дә: «Әтием, ике (өч) «бишле» алдым», – дип әйтә торган иде. Гомере кыска булса да, никадәр бәхет, сөенечле мизгелләр бүләк иткән бала ул безгә. Мең рәхмәтле мин аңа. Урыны оҗмахта булсын баламның, – ди әтисе.

«УЛ ИҢ ЯХШЫ УКУЧЫБЫЗ ИДЕ»

Айдар Хәмдеев укыган мәктәпкә кереп, аның укытучылары белән дә күрештек. «Мәктәп, авыл өчен бик зур югалту бу. Бүген дә аңыбызга килә алмыйбыз әле», – дип каршы алды алар безне.

– Бер генә бәйрәмебезнең дә Айдарсыз узганы юк иде. Матур җырлый иде, мәктәп алдынгысы булды. Бик тәрбияле гаиләдә үскән бала. Әти-әниләре дә мәрхәмәтле кешеләр, әбисе дә башлангыч сыйныф укытучысы иде. Аның турында бер генә кеше дә бер начар сүз әйтмәс. Аңа шелтә белдерерлек тә түгел иде бит. Гел «бишле» билгеләренә генә укыды. Һәр темага үз фикере булды, – ди директор урынбасары Миндания Ибниаминова.

– Бер сеңлесе дүртенче сыйныфта укый, шуны җитәкләп кенә йөртте бит. Туганнарын үлеп яратты. Айдар бик пөхтә, тормышка бик яраклашкан малай иде. Беркем дә аның кебек булдыра алмый. Суда батмый, утта янмый кебек иде югыйсә, күзләр дә тигәндер инде аңа. Анда да яхшылар кирәктер, күрәсең, – ди инглиз теле укытучысы Минслу Сөләйманова, күз яшьләре аша.

Әлеге кайгыны мәктәп директоры Фәниз Камалдинов да бик авыр кичергән. Үзе башка эшләр белән йөргәнлектән, аның тормыш иптәше, шушында ук лаборант булып эшләүче Алсу ханым белән аралаштык.

– Фәниз дә бик борчылды. Өйдә вакытта үзара сөйләшкәндә: «Алсу, юк бит инде ул бала. Әти-әнисе җир куенына илтеп сала бит инде аны», – дип елады. Шушы мәктәптә егерме ел эшли инде ул. Мондый зур кайгы кичергәнебез юк иде әле, ди. Нинди генә техника, компьютер көйсезләнеп торса да, үзем дә шундук Айдарга мөрәҗәгать итә идем. Тиз генә ясап та бирә иде, – дип искә алды ул.

Сыйныфташлары да иптәшләренең фаҗигале үлемен бик авыр кичергән.

– Бу хәбәрне ишеткәч, кан басымым күтәрелде, хәлем китте, – ди бер парта артында утырган дусты Ришат.

***

– Айдар туган көн бик буранлы иде. Җир куенына салганда да шундый ук һава торышы булды. Ул үлгән көнне бөтен дөнья ап-ак карга төренгән иде бит. Ашыгыч ярдәм дә тиз генә килеп җитә алмады. Җеназа күтәреп барган кешеләр агым кебек агылдылар, – ди әнисе, күз яшьләренә буылып.

Тугыз ай буена йөрәк астында йөртеп, җил-яңгыр тидермичә үстергән шулкадәр тәртипле, акыллы, бар яктан булган газиз баласын салкын җир куенына салган ананы юатырдай нинди сүзләр тапмак кирәк соң? Мин дә: «Ходай сабырлык бирсен үзегезгә. Улыгызның авыр туфрагы җиңел булсын», – дип кенә әйтә алдым.

Хәмдеевләрнең бер туганнары Айдарны җирләгән көнне төш күргән. Айдар тирә-юнен ямь-яшел чирәм каплаган чиста сулыкта юына, ди, имеш. Оҗмахта инде бу бала, дип юраганнар төшне туганнары. Әлеге язмабыз да Айдарның якты рухына дога булып барып ирешсен иде. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун…

7 МАЙ – ХАЛЫКАРА РАДИО КӨНЕ

«Тыңлагыз, тыңлагыз! Казан сөйли!» 90 еллык тарихы булган Татарстан радиосының беренче авазы нәкъ менә шулай яңгыраган. Кайчандыр халык өчен Шамил Усманов кебек янып йөргән фидакарь милләттәшләребезнең безгә калдырган мирасы ул. Халыкара радио көне һәм якынлашып килүче зур юбилейлары алдыннан, радионың бүгенгесе, эчке «кухнясы» белән танышырга булдык.

Казан – 99,2 ФМ
Әлмәт – 103,9 Мгц
Яр Чаллы – 92,1 ФМ
Түбән Кама – 101,1 ФМ
Буа – 103,8 ФМ
Нурлат – 70,46 Мгц
Лениногорск – 68,63 Мгц

КАЗАН СӨЙЛИ!

Алисә САБИРОВА

ҺӘР КЕШЕ – ТАРИХ, ҺӘР ТАПШЫРУ – ДӨНЬЯ

Редакциянең кайсы гына бүлмәсенә кермә, кайда да легендар, фидакарь журналистлар белән очрашасың. Ә алар алып барган тапшырулар – бер гасырга якын эфир киңлекләрен тотып торган радионың йөзек кашы. Сәяси-иҗтимагый тапшырулар шеф-редакторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Йолдыз Крепостина җитәкләгән «Идел белән Урал арасында» тапшыруын гына алыйк, киләсе елга ул 60 еллык юбилеен билгеләячәк.

– Шушы вакыт аралыгында тормыш та, дәүләт сәясәте дә үзгәрде, ләкин программа, радио үзе дә төп принципларына тугры булып калды. Җиде төбәкнең дә үзенчәлеге, үзләренә генә хас гадәтләре бар. Эфирга чыкканда, без «алтын урталык»ны табарга тырыштык. Адым саен халыкара конфликтлар чыгып тора. Бездә мондый хәлләр булмасын өчен, үз эшебездән тайпылмаска тырышабыз, – ди Йолдыз Крепостина.

Радиода ул инде 1993 елдан бирле эшли, ә радиожурналны 2001 еллардан җитәкли.

– Хәзер радионың техник яктан мөмкинлекләре чиксез. Элек исә һәр сюжетны автобус, поезд, кешеләр аша җибәрә идек. 1988 елда безгә Коми Республикасы кушылды. Анда әле бүген дә барып җитүләре кыен, ә ул вакытта элемтә бары почта аша гына оештырыла иде. Бер сюжетны икеөч атна көтәргә туры килде, – дип искә ала ул елларны Йолдыз Крепостина.

Бәхетле гаилә серләрен 30 ел эфир киңлекләрендә «Пар канатлар» тапшыруын алып барган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәзин Нуруллиннан да яхшырак белүче юктыр. Былтыр аның да радио ишекләрен тәүге кат ачып керүенә – 45 ел.

– Укуның беренче елында ук җырлар авторы Кәүсәрия Шафикова турында әзерләгән материалым эфирга чыкты. Шул вакытта тапшыруларга атналык күзәтү ясаган режиссер Руслан Әхмәтҗанов, эшемне уңай бәяләп, «өметле малай, эшкә җәлеп итәргә кирәк» дип, мине радионың даими хәбәрчесе итте. Инде III курста гаилә корыум да эшкә иртә урнашуыма бер сәбәпче булгандыр. Гаиләне түендыру өчен бик күп яздым. Ә «Пар канатлар»ны миңа остазым Борис Зиннәтуллин тапшырды, ул башлаган эш бу, – ди Рәзин абый.

8 май көнне Камал театрында «Пар канатлар» туган көнен гамьле бер концерт белән дә билгеләп үтә әле.

– Беренче тапшыруыбыз геройлары Асия белән Альберт Габдуллиннар иде. Берсе – гомер буе трамвай йөртүче, икенчесе эшче булган гади совет гаиләсе алар. Кызганыч, Асия апа бүген безнең арабыздан китте. Ә менә Альберт абый сәхнәгә дә күтәреләчәк әле, – ди Рәзин абый.

Редакциядә «һ»не «х» дип әйтсәң, шунда ук урыныңа утырталар. Татар теле сафлыгы өчен инде 40 елга якын Рөстәм Фәйзуллин җитәкчелегендә «Тел күрке – сүз» дигән тапшыру көрәшә. Биредә телне тирәнтен белгән Вахит Хаков, Илдар Низамов, Рүзәл Юсупов кебек белгечләрнең чыгышын тыңларга була. Аеруча яшь язучылар, шагыйрьләрнең яраткан тапшыруы бу.

Нәни тыңлаучылар өчен дә «Көмеш кыңгырау», «Сердәшханә», «Гөлбакча», «Табигать дуслары», «Язучылар – балаларга» дигән тапшырулар әзерли радио. Аларны язучы, журналист, рәссам Дания Гайнетдинова алып бара. Әдәби-нәфис тапшырулар – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Нәсим Акмал карамагында. Ул – данлыклы «Татарстан дулкынында» тапшыруының мөхәррирләренең берсе. Журналист Ләйсән Фәизова рус телендә иҗат итүче татар язучыларын барлый. Гомумән, радиода икетелле мохит. Фәнис Мөхәммәтов, Вәзирә Зыятдинова, Миләүшә Җиһаншина, Гөлназ Гыйлемҗанова, Гөлнара Нурмөхәммәтова... – Татарстан радиосы хезмәткәрләре – һәрберсе аерым игътибарга лаек.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә радиотапшырулар хезмәтен Тәүфыйк Сәгыйтов җитәкли. Бу көннәрдә ул үзе дә 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Гомерен радиога багышлаган шәхес. Радиодагылар аңа сокланып, аннан үрнәк алып иҗат итәргә тырыша.

ТЕАТР – МИКРОФОН АЛДЫНДА

Кечкенә генә бер бүлмәдә Татарстан радиосының «алтын фонды» саклангән. Дөресрәге, барлык татар дөньясының «алтын фонды». Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның Тукай турында әйткән сүзләре, Туфан Миңнуллин, Әмирхан Еники кебек язучыларыбыз тавышы, беренче драма әсәрләре... – барысы да бу серле тартмаларда яшеренгән. 2000нче еллар башында тавышларны дискларга яздыру, компьютерлаштыру эше башланган.

Татарстан радиосы – тыңлаучыларны театр дөньясы белән таныштыручы бердәнбер радио да бит әле. Менә бу тартмаларда да моннан 30 ел элек сәхнәләштерелгән «Зәңгәр шәл», М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт театрының «Ак калфагым төшердем кулдан», Казах дәүләт театрының казах телендә уйнаган «Галиябану»лары саклангән. Заманында, тавышларын радиога яздыру өчен, театрлар ярты ел алдан чиратка баса торган булганнар.

Радионың тавыш режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Гыйләҗева ул елларны сагынып искә ала.

– Чит-ят тавыш кермәсен дип, без спектакльне төнлә яздыра идек. Артистлар да радиога бик теләп йөрде. Радиоспектакль аларның тавышын мәңгеләштерү дигән сүз бит. Иҗат эше авыр, ләкин бик рәхәт. Артистлар белән эшләү – үзе бер вакыйга. Алар спектакльдән соң арып яисә артык ял итеп килергә мөмкин. Бер-берсен үпкәләтмичә генә, тавышларын бер тонда яңгыратырга тырышасың. Радиоспектакль өчен артистларга да, журналистларга да гонорар түләнә иде. Беренче гонорар алгач, ялгыш биргәннәрдер, дип бик курыктым. Ул безнең хезмәт хакы кадәр иде. Сәхнәдә барган спектакль радиоспектакльдән бернichек тә аерылмады. Әле радиода актерлар тырышыбрак та уйный иде. Студиядә актерлар чын спектакль куйды. Йөгергәннән соң сөйләшкән тавыш кирәк булса, баштa артистларны зал буйлап йөгертә идек, аннан микрофонга бастырып сөйләштерә идек, – ди Әлфия апа.

Радиода соңгы спектакль XXI гасыр башында яздырыла. Бүген дә һәр дүшәмбе, шимбә, якшәмбе көннәрендә әлеге спектакльләрне тыңлап була. Озын тәнәфестән соң спектакль яздыру кебек җаваплы эшне яшьләр үз кулына алган. Бу эштә бигрәк тә журналист Раил Садри (Садретдинов) тырыша.

КЫЙБЛАСЫНА ТУГРЫ УЛ

Татарстан радиосы – дикторлык институтын саклап калган бердәнбер радио да әле. Әдәби татар телендә чиста сөйләшергә өйрәнәсең килсә, 99,2 FM киңлекләрен тыңларга кирәк. Радионы исә диктор Татарстанның халык артисты Тәлгать Хәмәтшинның бәрхет тавышыннан башка күз алдына да китереп булмый. Заманында, аның тавышына сокланып, радиога өем-өем хатлар агылган.

– Университеттан соң Оренбург өлкәсендәге Тодский лагеренда хәрби җыенда булдым. Кич иде. Шунда татар көен ишеттем. Бу тавыш каян килә икән дип, урман эчендәге палаткалар буйлап эзләп киттем. Килсәм, Казан сөйли икән. Бу вакытта мин Татарстан радиосында эшләрмен дип күз алдына да китермәдем, – ди ул.

Тәлгать абыйның диктор булу теләге инде мәктәптән үк килә. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фоат Галимуллинның «радиода эшләгән барлык дикторлар да югары педагогик белемле» дигән сүзләрен истә тотып, Башкорт дәүләт университетының татар һәм рус әдәбияты бүлегенә укырга керә. Ләкин дикторлык фәкать конкурс аша гына алына торган һөнәр. Укуын тәмамлагач, Тәлгать абыйны да, ун кешелек комиссия алдында тыңлап, эшкә алалар.

– Бүген радиолар бик күп, теләсә кем эфирга чыга, теләсә нәрсә сөйли. Ләкин дикторлык хезмәтен саклау – татар телен саклап калу дигән сүз ул. Бу мәсьәләгә глобаль карарга кирәк. Радио эше һәрчак вакыт белән бәйле, тормышыбызны секундлар хәл итә. Иртәнге 6 сәгать 2 минутта тапшыруыбыз башлана иде. Шул вакытта син инде студиядә утырып торырга тиеш. Тәрле очракларга юлыктык, ләкин эфирга бер тапкыр да соңга калган булмады. Бик соңлагангда, автобус шоферы янына басып ашыктыра идем. Хәлемә керәләр иде анысы, – дип искә ала Тәлгать абый.

Бу радиодан сез беркайчан да очраклы җырлар ишетмәссез. Җырны да алар тәрбия чарасы буларак кабул итә. Тикмәгә генә Татарстан радиосын мәдәният-сәнгать оешмалары «әнисе» димиләр инде. Заманында М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры симфоник оркестры биредә канат чыгарган. Радио үзе бер филармония булган. Музыкаль бүлекне данлыклы композиторыбыз Салих Сәйдәшев җитәкләвен генә искә төшерсәк, радионың ни кадәр дәрәҗәле икәнен чамалап була.

– Татарстан радиосы беркайчан да үз кыйбласыннан тайпылмый. Вак иләктән иләнгән, зәвыклы җырлар гына бирергә тырышабыз, – ди биредә эшләүче хезмәткәрләр.

Ләкин бу гел иске җырлар гына яңгыраталар дигән сүз түгел, радио даими рәвештә яшь җырчыларның, композиторларның эшләре, үзешчән артистлар иҗаты белән дә таныштыра.

Коллегаларыбыз – Татарстан радиосы хезмәткәрләрен олы юбилейлары белән котлыйбыз. Үз кыйблагызга тугры булып, тамашачыларыгызның рәхмәтен ишетеп эшләргә язсын!

ӘПТЧИ!

Аллергиядән ничек сакланырга?

Аллергиядән интеккән кешеләр өчен авыр чор башланды. Агачлар бөреләнгән, үсемлекләр чәчәк аткан чорда күпләр күздән яшь агу, төчкерү, томау төшүдән зарлана. Аларга нинди саклану чаралары кулланырга һәм, гомумән, аллергия авыруының киң таралыш алуы нәрсәгә бәйле? Шушы турыда без республиканың Клиник иммунология үзәге мөдире, югары категорияле табиб иммунолог-аллерголог Алексей Лунцов белән сөйләштек.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Алексей Владимирович, соңгы ун елда аллергия дигән авыру тагын да ешрак очрый башлады кебек. Моның сәбәбе нидә икән?

– Бу чыннан да шулай. Алай гына да түгел, XXI гасыр башында авыручылар саны һәр ун ел саен икеләтә артты. Чөнки яшәү рәвеше, гигиена шартлары, туклану яхшырды, әмма икенче яктан табигый микрофлора белән бәйләнеш чикләнелде. Ә бит әлеге бәйләнешкә без гасырлар буена ияләштек. Иммун системасы микробларны һәм паразитларны һәрдаим очратып, алар белән көрәшеп ныгый иде. Нәтиҗәдә, яшәү шартлары яхшыргач, моңа кадәр зарарсыз булып саналган матдәләргә организмның сизгерлеге артты. Әлеге матдәләр дигән вакытта нинди дә булса химик ингредиентларны, ризык, йон, тузан, чәчәк серкәсе яки хайваннарны аңларга кирәк. Тормыш шартлары начар булган, инфекцияләр, һәр төрле авырулар мыжгып торган Африка илләрендә аллергия сирәк очрый. Чөнки андагы халыкның иммун системасы бөтенләй башка проблемалар, инфекцияләр белән көрәшә. Ә Европа, АКШ һәм Россия кебек алга киткән илләрдә аллергиядән интегүчеләр, киресенчә, елдан-ел арта. Мәсәлән, астма белән бәйле проблемаларның 10-15 процент кешедә очравы билгеле.

– Ризыкка аллергия, атопик дерматит һәм поллиноз бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Атопик дерматит – тән тиресенең ялкынсынуы. Бу, гадәттә, сабыйларда беренче тапкыр ризык куллана башлаганда күзәтелә. Еш кына төп аллерген булып сыер сөтендәге аксым тора. Шушы ук күренешне ризыкка булган аллергия дип тә аңларга була. Ләкин монысының төп аермасы шунда – ул төрле характерда булырга (тиз уза торган, кискен, озакка сузылучан), хәтта анафилактик шокка кадәр җитәргә мөмкин. Ә поллиноз – ел фасылына бәйле аллергия. Бу билгеле бер үсемлекләрнең һәм агачларның чәчәк аткан вакытына туры килә. Иң элек ул аллерген һава аркылы күзгә, борынга, сулыш юлларына эләгә.

– Атопический аллергиядән интеккән балаларда авыру билгеләре үсә төшкәч тулысынча бетәме, әллә ул зуррак формага – поллинозга күчәме?

– Бу чыннан да мөһим сорау. Дөрестән дә, билгеле бер вакыттан соң аллергия билгеләренең эволюциясе башланырга мөмкин. Аны хәтта балаларда «атопический марш» дип тә йөртәләр. Сабый чагыннан ук билгеле бер ризыкны кабул итмәгән организм икеөч яшькә һава белән бәйле аллергеннарга – тузанга, чәчәк серкәсенә сизгерлеген арттыра. Алга таба балада астма да башланырга мөмкин. Әмма барлык балада да шулай була, дип кистереп әйтергә ярамый. Бәхеткә, ризыкка, мәсәлән, шул ук сыер сөтенең аксымына булган аллергия еш кына уза да. Әлеге аллергиядән яшүсмер вакытта котылырга мөмкин. Тик билгеле бер төрдәге ризыкларга аллергия гомер буена сузыла ала. Мәсәлән, диңгез ризыкларына һәм арахиска.

– Иммун системасы башта ук билгеле бер матдәгә сизгер буламы? Гомумән, булачак ата-анага профилактика максатыннан ни дә булса эшләргә кирәкме?

– Аллергия реакцияләренә каршы иммунитетның җавабы – катлаулы процесс, чөнки ул күп геннарның эшчәнлеге белән бәйле. Әгәр аллергия әни яки әти кешедә генә күзәтелсә, балада бу авыру башлану куркынычы – 30 процентка, икесендә дә булса, 80 процентка кадәр арта. Профилактика дигәндә, мөһим факторларның берсе – булачак ананың тәмәке тартмавы. Аннан соң тикшеренүләр күрсәткәнчә, авыл балалары аллергия белән сирәгрәк авырый. Чөнки алар кечкенәдән үк хайваннарны күреп, белеп, тотып карап үсә, җир, туфрак белән бәйләнешләре тыгызрак була. Шәһәр баласы исә гомеренең беренче айларында бөтенләй стериль шартларда тәрбияләнә. Аннан соң күкрәк сөте белән дә мөмкин кадәр озаграк тукландырырга кирәк. Ким дигәндә – алты ай. Иң яхшысы, әлбәттә, сабыйның 1,5 яшькә кадәр күкрәк сөте ашавы яхшы.

– Хәзерге вакытта актуаль темаларның берсе – язгы аллергия турында да берничә киңәш аласы килә иде.

– Язгы аллергиянең төп билгеләре – күздән яшь агу, кычыту, бит һәм тән шешенү, томау төшү, туктаусыз төчкерү. Беренче тапкыр күзәтелгәндә, авыру үз-үзенә дөрес диагноз куя алмаска да мөмкин. Шуңа күрә әлеге билгеләр вакытында тән температурасы югары булмаса, шушы халәт атнадан артыгракка сузылса, табиб-аллергологка барырга кирәк. Ул авыруның хәле начарланган чорда махсус тестлар ясарга, кан тапшырырга тиеш була. Нинди препарат кулланырга кирәклеген исә һәр кешегә карата индивидуаль хәл ителә. Әгәр аллергия һәр яз саен кабатлана икән, авыру үз табибы белән киңәшләшеп, алдан ук саклану чараларын күрергә тиеш. Мондый очракта үзенчәлекле монотерапия үткәрү яхшы. Бу дәвалауны агачлар бөреләнә, чәчәкләр ата башлаганчы ике-өч ай алдан башлыйлар. Ул билгеле бер, мәсәлән, каен чәчәге серкәсе аллергенын организмга аз-азлап арта барган дозада кертүдән гыйбарәт. Моның өчен инъекция, дару төймәсе, махсус тамчылар файдаланыла. Мондый дәвалау фонында организмның реакциясе үзгәрә. Һәм бу яңа типтагы аллергия барлыкка килмәсен, шулай ук астманы дәвалау өчен профилактика да булып тора.

ЯЗГЫ АЛЛЕРГИЯ БЕЛӘН НИЧЕК КӨРӘШЕРГӘ?

ТӨП АЛЛЕРГЕННАР

АВЫРУ БИЛГЕЛӘРЕ

ДИАГНОСТИКА ЧАРАЛАРЫ аллергенга проба, кан анализы

ПРОФИЛАКТИКА

Магнит давыллары

16-24 май көннәрендә озакка сузылган, көчле магнит давыллары күзәтеләчәк, дип кисәтә белгечләр. Бу көннәрдә метеосизгерлеге югары булучылар хәлсезлектән һәм баш авыртудан зарланырга мөмкин. Шулай ук хроник авырулары булган кешеләргә азрак эшләп, күбрәк ял итәргә киңәш ителә.

Аллергиядән интегүчеләргә ел дәвамында чикләвек, кызыл алма, чия, төче чия, помидор, чи кишер, персик, абрикос ашамаска киңәш ителә.

8 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Время собирать камни» . Телесериал (16+)
10:50 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Гетеры майора Соколова». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 Р. Сабыр. «Абага алмасы ачы була». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
17:00 «Артур-Марат». Концерт (6+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Мәхәббәт диңгезе». Рөстәм Асаев җырлый (6+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Перед рассветом». Художественный фильм (16+)
23:30 Документальный фильм (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Йөрәктән – йөрәккә» (12+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Мәхәббәт сынаулары». Телефильм (12+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:35 «Ачытау». Зөһрә Шәрифуллина җырлый (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 Т.Миңнуллин. «Телсез күке». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле (12+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «20 ел бергә». Фәридә-Алсу концерты (6+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Туган җир» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Сугыш чоры җырлары» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 Т.Миңнуллин. «Нәзер». Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры спектакле (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
Вещание не предусмотрено

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Нормандия – Неман». (12+)
08.25 Х/ф «Небесный тихоход».
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф Премьера. «Моя линия фронта». (16+)
11.15 Х/ф «Битва за Севастополь». (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 Д/ф «Битва за Севастополь». (12+)
13.55 Х/ф «А зори здесь тихие...» (12+)
17.15 Чемпионат мира по хоккею-2017. Сборная России – сборная Германии. Прямой эфир из Германии. В перерыве – Вечерние новости с субтитрами.
19.25 Т/с Премьера. «По законам военного времени». (12+)
21.00 Время.
21.20 Т/с «По законам военного времени». (12+)
23.50 Х/ф «Баллада о солдате».
01.35 Х/ф «В двух шагах от «Рая». (12+)

РОССИЯ 1
04.25 Х/ф «Операция «Тайфун». Задания особой важности». (12+)
07.40 Т/с «Полоса отчуждения». (12+)
11.00 Вести.
11.20 Т/с «Полоса отчуждения». (12+)
15.25 Т/с «Карина Красная». (12+)
20.00 Вести.
21.00 Т/с «Карина Красная». (12+)
00.00 Х/ф «День Победы». (12+)
01.05 Х/ф «Горячий снег».

9 МАЙ – СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
03:40 «Щит и меч». Многосерийный художественный фильм (12+)
09:30 Новости Татарстана (12+)
09:40 Парад войск Казанского гарнизона в честь 72-й годовщины победы в Великой Отечественной войне. Прямая трансляция (0+)
10:50 Праздничный концерт (0+)
11:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
11:45 Продолжение Праздничного концерта (0+)
13:00 «Путь моего отца». Телеочерк (6+)
13:30 Новости Татарстана (12+)
13:50 «9 Мая». Поёт Ренат Ибрагимов (0+)
14:45 Казань. Бессмертный полк-2017. Прямая трансляция (0+)
16:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
16:45 Казань. Бессмертный полк-2017. Продолжение прямой трансляции (0+)
17:30 «Перед рассветом». Художественный фильм (16+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
18:55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма...». Минута молчания (0+)
19:01 «Перед рассветом». Продолжение художественного фильма (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 Парад войск Казанского гарнизона в честь 72-й годовщины победы в Великой Отечественной войне (0+)
21:00 «Последний герой». Документальный фильм (0+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:05 Казань. Бессмертный полк-2017 (0+)
00:00 «Время собирать камни». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Хәтер...». Әдәби музыкаль композиция (6+)
07:00 А.Гыйләҗев. «Яра». Түбән Кама татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:15 «Сугыш чоры җырлары» (6+)
09:40 Бөек Җиңүнең 72 еллыгына багышланган тантаналы хәрби парад. Турыдан-туры трансляция (0+)
10:50 Бәйрәм чараларының трансляциясе (0+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:10 Бәйрәм чараларының дәвамы (0+)
13:00 Р.Харис. «Күзләреңнән үбеп...» С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле (12+)
14:25 «Ватандашлар». Фәрит Яруллин (6+)
14:45 Казан. «Үлемсез полк-2017» . Турыдан-туры трансляция (0+)
17:30 «Сугыш чоры җырлары» (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Татарлар» (12+)
18:55 Фашизмга каршы сугышта һәлак булганнарның якты истәлегенә... Бер минутлык тынлык (0+)
19:00 Бөек Җиңүнең 72 еллыгына багышланган тантаналы хәрби парад (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Үлемсез полк-2017» (0+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
20.40 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Новости.
05.10 «День Победы». Праздничный канал.
09.50 Новости.
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы.
11.00 Новости с субтитрами.
11.30 Х/ф «Офицеры».
13.00 Концерт, посвященный юбилею фильма «Офицеры» в Кремлевском Дворце.
14.30 Новости с субтитрами.
15.00 «Бессмертный полк». Прямой эфир.
17.30 Х/ф Премьера. «Двадцать восемь панфиловцев». (12+)
19.15 Премьера. «Будем жить!» Торжественный концерт ко Дню Победы.
21.00 Время.
21.45 «Будем жить!» Торжественный концерт ко Дню Победы.
22.20 Х/ф «В бой идут одни «старики». Легендарное кино.
23.50 Х/ф «Живые и мёртвые».
3.00 Х/ф «Женя, Женечка и «Катюша».
4.20 «Песни Весны и Победы».

РОССИЯ 1
03.55 Х/ф «Последний рубеж». (12+)
05.50 «День победы». Праздничный канал.
10.00 Москва. Красная площадь. Военный парад, посвящённый 72-й годовщине победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.
11.00 «День победы». Праздничный канал.
11.45 Х/ф «Сталинград». (16+)
14.00 Вести.
15.00 «Бессмертный полк». Шествие в честь 72-й годовщины Великой Победы.
18.00 Праздничный концерт, посвящённый Дню Победы.
20.00 Вести.
20.40 Вести. Местное время.
20.55 Т/с «Истребители. Последний бой». (16+)
22.00 Праздничный салют, посвящённый Дню Победы.
22.15 Т/с «Истребители. Последний бой». (16+)
04.00 Д/ф «Иду на таран». (12+)

10 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар» . Телесериал (12+)
10:00 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
10:50 «Туган җир» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Каравай» (6+)
13:30 Документальные фильмы (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Энид Блайтон. Книга приключений». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Вадимом Кешнером» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
00:00 «Видеоспорт» (12+)
00:30 «Участок». Телесериал (16+)
01:30 «Таяну ноктасы» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Күңел – җыру». Георгий Ибушев турында телеочерк (6+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Кыр казлары артыннан». Мәсгут Имашев турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)
00:15 «Туган җир» (12+)
00:40 «Татарлар» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)
23.40 «Вечерний Ургант». (16+)
0.15 Ночные новости.

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Между любовью и ненавистью». (12+)
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

11 МАЙ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 « Последний янычар » . Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок». Телесериал (12+)
13:00 «Каравай» (0+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Ильдаром Ягафаровым» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Күңелем назлары җырымда чагыла...» Татарстанның халык артисткасы Флюра Сөләйманова турында телеочерк (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк (12+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Национальный вопрос и ответ»
9.20 «Город мастеров»
9.35 «Ревнители древлего благочестия». Телефильм
11.40 «Вести-Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)
23.40 «Вечерний Ургант». (16+)
00.15 Ночные новости.
00.30 Х/ф «Мумия: Гробница Императора Драконов». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Между любовью и ненавистью». (12+)
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

12 МАЙ – ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Нәсыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
10:50 «Нәсыйхәт» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Участок» . Телесериал (12+)
13:00 «Башваткыч» (6+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Все суры Корана» (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Тамчы-шоу» (0+)
15:40 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
15:55 «Зебра» (0+)
16:05 «Энид Блайтон. Секретная книга». Телесериал (6+)
17:00 «Ак чәчәкләр». Телесериал (6+)
18:00 «Туган җир» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Белем дөньясы» (6+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «ДК» (12+)
21:15 «Дорога без опасности» (12+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Наша республика. Наше дело» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Нәсыйхәт» (6+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Музыкаль каймак» (12+)
10:10 «Ком сәгате» (12+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Кичке аш» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Нәсыйхәт» (6+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлы-моңлы балачак» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Гашыйк йөрәк». Телесериал (12+)
19:10 «Аклык турында җыр». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиева турында телеочерк (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Ватандашлар» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Музыкаль каймак» (12+)
22:40 «Аклык турында җыр». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиева турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Иҗат»
9.30 «Халык җәүһәрләре»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20 «Вести Приволжского федерального округа»
20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Жди меня.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 Т/с Премьера. «Власик. Тень Сталина». (16+)
23.35 «Вечерний Ургант». (16+)
00.20 Т/с «Фарго». Новый сезон. «Городские пижоны». (18+)
01.25 Х/ф «Поймай толстуху, если сможешь». (16+)
03.30 Х/ф «Руководство для женатых». (12+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Между любовью и ненавистью». (12+)
23.30 Х/ф «Красавец и чудовище». (12+)

13 МАЙ – ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Автомобиль» (12+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (0+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
13:30 «Созвездие – Йолдызлык-2017» (0+)
14:30 З. Хаким. «Утрау». Әлмәт татар дәүләт ңрама театры спектакле (12+)
16:30 «Татарлар» (12+)
17:00 «Без тарихта эзлебез» (6+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «КВН РТ-2017» (12+)
19:00 Документальный фильм (12+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар» (12+)
20:30 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:30 Новости в субботу (12+)
22:00 «Ближе, чем кажется». Художественный фильм (6+)
23:45 «Воспоминания о будущем». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Кабатлана язлар». Марсель Вәгыйзов концерты (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:40 И.Юзеев. «Гашыйклар тавы». Чаллы татар дәүләт драма театры спектакле (6+)
14:10 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
17:30 «Нәсыйхәт» (6+)
18:00 «Әйдә, дустым, уйнат гармуныңны». Фән Вәлиәхмәтов концерты (6+)
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 Г.Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле (12+)
23:50 «Гомер бәйрәме!». Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллинаның юбилей кичәсе (6+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести – Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Один шанс из тысячи». (12+)
08.00 Играй, гармонь любимая!
08.45 М/с «Смешарики. Новые приключения».
09.00 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф Премьера. «Федор Бондарчук. Счастлив. Здесь и сейчас». (12+)
11.20 Смак. (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.15 «На 10 лет моложе». (16+)
14.00 Концерт Кристины Орбакайте.
15.40 Премьера. «Вокруг смеха».
17.15 Чемпионат мира по хоккею-2017. Сборная России – сборная Словакии. Прямой эфир из Германии. В перерыве – Вечерние новости с субтитрами.
19.25 «Угадай мелодию». (12+)
20.00 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
21.00 Время.
21.20 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым. (16+)
23.00 Х/ф Премьера. «Руби Спаркс». (16+)

РОССИЯ 1
05.15 Х/ф «В бегах». (12+)
07.10 «Живые истории».
08.00 Вести. Местное время.
08.20 Россия. Местное время. (12+)
09.20 Сто к одному.
10.10 «Пятеро на одного».
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 «Измайловский парк». Большой юмористический концерт. (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Фото на недобрую память». (12+)
16.20 «Золото нации».
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.00 Х/ф «Цвет спелой вишни». (12+)
00.50 Х/ф «Звёзды светят всем». (12+)

14 МАЙ – ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 Документальный фильм (12+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Созвездие – Йолдызлык-2017» (0+)
15:00 «Ком сәгате» (12+)
16:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 «Болгар радиосы» концерты (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
23:00 «Заказ». Художественный фильм (18+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 П.Коэльо. «Алхимик». Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле (12+)
07:30 «Зурлар өчен әкият». Популяр җырлар авторы Ләйлә Дәүләтова концерты (6+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 ТВ фондыннан. «Эш күрсәткән ирне ил онытмас». РафаэльМостафин истәлегенә (6+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Нәсыйхәт» (6+)
13:30 «Рәгъдечә яшьнәп яшәү». Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәгъде Халитовның юбилей кичәсе (6+)
15:15 «Сезгә кайнар мәхәббәтем». Вил Усманов концерты (6+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Болгар радиосы» концерты (6+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Язмышларым сиңа бәйләнгән...». Рөстәм Закиров һәм Люция Мусина концерты (6+)
22:25 «Шаян хәлләр» (16+)
23:20 «Халкым минем» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Судьба человека».
08.05 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.20 «Идеальный ремонт».
13.20 Д/ф «Теория заговора». (16+)
14.25 Д/ф Премьера. «Страна советов. Забытые вожди». (16+)
16.30 Премьера. «Шансон года».
18.20 «Аффтар жжот». (16+)
19.30 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига. (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Х/ф «В бегах». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 Смеяться разрешается.
13.10 «Семейный альбом». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Шёпот». (12+)
16.15 Х/ф «Смягчающие обстоятельства». (12+)
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

«ТАТАРСТАН» радиосы

8 МАЙ – ДҮШӘМБЕ

10.10 Чыңгыз Айтматов . «Малай белән очрашу». Радиотамаша
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.10 Яңалыклар. Новости
13.20 «Җиңү язы». Концерт

9 МАЙ – СИШӘМБЕ

ҖИҢҮ КӨНЕ
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.00-13.10 Вести радио России
13.10 Яңалыклар. Новости. Спецвыпуск
13.40 Җиңү җырлары, маршлар
13.55 Прогноз погоды, программа передач
14.00 Трансляция радио России

10 МАЙ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Муса Җәлил шигырьләренә язылган җырлар

11 МАЙ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Перекресток»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
10.35 «Время молодых»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Офыклар»
18.25 Композитор Латыйф Хәмиди әсәрләреннән концерт

12 МАЙ – ҖОМГА

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Вдохновенья миг»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 Рөстәм Яхин әсәрләре
18.25 Башкортстан артистлары концерты

13 МАЙ – ШИМБӘ

10.10 « Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Татар халык көйләре
15.10 Кыска хикәяләр

14 МАЙ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10,11.00-12.10,13.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35 «Шигърият». Г.Мөхәммәтшин
16.10 Фоат Садриев. «Таң җиле».

ЯЛ ПОЧМАГЫ

Аермалар тап





СКАНВОРД

Мәркәзе – Гавана шәһәре
Урта Азия агулы үрмәкүче
Әкияти карчык
Ленинград өлкәсендәге күл
Әдәби жанр
Башкортстандагы район
Ачның киресе
«Эссе» төркеме җырлый
Сугыш
Бәрәңге бакчасы
Мәдхия шигырь
Кинәт һәм көчле һөҗүм
Иделнең борынгы атамасы
Туп футбол кырыннан тыш
Шахматта атның «күршесе»
Төньякта этләр җигеп йөрү өчен чана
Теш ите
Җырчылар Пьеха һәм Михайлов
Судно борты
Кисәкчә
Исерек
Алгының антонимы
Ручка
Каскадер аны ясый
Урмандагы ачык урын
Аллегрова бала чакта
Атны куу
Латвия акчасы
Кабилә
Рус халык эпик җыры баһадиры
Тәртип бозучы
Дару
Очсыз
Элекке Горгиппия шәһәре
Актриса ... Зелёная
Татарстандагы шәһәр
Талгын
III зат алмашлыгы
Җырчы ... Зиннәт
Югары уку йорты җитәкчесе
Очко
Вицинның кинодагы кушаматы
Кызыл төс (инглизчә)
Җәрәхәт
Татарстан Республикасы
Негроид
Кама елгасы кушылдыгы
Дистанция
Америка актёры Лоренцо
Биюдәге ритмик хәрәкәт
Кытайда корылык Алласы
Алпавыт биләмәсе
Теркәгеч
Винни-Пухның дусты
Күләм үлчәү берәмлеге
Газап
Нота
Туполев очкычы
Химик матдә яки коелма
Норвегия футбол клубы
Әләм
Үлән белән тукланучы бөҗәк
Үлчәм

Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: Хәйруллин, тарантул, яу, ындыр, Бакалы, ода, лаг, урт, арткы, алан, да, салмыш, Анапа, алар, Рина, Трус, юнь, ТР, раса, салмак, яра, Ба, Лидия, па, ара, ки, куб, металл, Ту, иза, флаг, Нурия, саранча, размер.
Вертикаль буенча: хулиган, «Аспирин», каләм, убырлы, Азалия, трюк, Ладога, Ламас, ладья, роман, ректор, нарта, Иа, Куба, «Люн», удар, балл, тук, Ра, Ира, фа, аут, на, Ык, Стас, утар, «Авылга», Алабуга, лат, ред, ыру, Ландыш, Святогор.

ХӨКЕМ

Хөкем залында көр тавыш ишетелде. Ул, үз исемен ишетеп, дертләп китте. Урындыгына ныграк ябышты. Тик бу котылу юлы түгел, барыбер, урындыктан аерылырга туры киләчәк, аңа басарга кушалар иде. Ул, бөтен көчен җыеп, аягүрә басты. Бар күңеле үкенү, әрнү белән тулды. Шулай да котылу юлы булырга тиеш кебек иде. Тик хөкемдарның көр тавышы өметкә охшаш хисләрне шундук куып таратты:

– Сез хезмәт урыныннан бөтен көчегезне куеп тырышып эшләүдә гаепләнәсез!

Залдагы халыкның нәфрәтле карашы аңа төбәлде. Шулай булырга тиеш идедер, беркайчан да артыгын тырышмаган бу кешеләр алдында ул гаепле иде. Үзенең нәрсәдер эшләргә тырышуы белән генә дә ул бу кешеләрне кимсетә, булдыксызга чыгарырга тырыша, бер сүз белән әйткәндә, аларның яшәү рәвеше өчен куркыныч тудыра иде. Ә үз тормышыңа янаган бәндәгә берәү дә сөеп-яратып карый алмый. Бу кешеләр хаклы, ул гаепле иде.

Гаепләүче аның җинаятьләрен санап китте. Бер карасаң, артык һуш китәрлек нәрсәләр юк иде. Эшенә вакытында килә, җыелышларны калдырмый, ул җыелышларда эшлекле тәкъдимнәр кертә, алай гына да түгел, шул уйларын тормышка ашырырга маташа. Һәм тормышка ашыра да. Ә бу башкаларны да эшләргә мәҗбүр итә, гадәттәгечә эленке-салынкы гына йөрергә ирек бирми. Соңгы вакытларда аның шушы юньсезлеге аркасында беркемгә дә тынгылык калмаган, бөтен кеше дә эшләргә мәҗбүр ителгән, ә көче җитмәгәннәр хезмәт урынын калдырып китәргә мәҗбүр булган. Ә бу илдә эшсезләр саны артуга китергән. Менә бит ничек! Бу гади җинаять кенә түгел. Моннан сәясәт исе килә.

Гаепләүченең чыгышын алкышларга онытмадылар. Шулай булырга тиеш иде. Үз мәнфәгатьләрен яклаучыны халык ярата. Ә бу юлы мәхкәмә халык мәнфәгатьләрен яклый иде. Әллә ни әйтә алмады. Шулай да эшкә вакытында килүне гаепкә чутламаска тәкъдим итте, чөнки бөтен кеше дә шулай итә, ләкин эшкә килү әле ул эшләү дигәнне аңлатмый. Бу тәкъдим белән килештеләр.



Залдагы халык ризасызлык белдермәсә дә, гаепләүченең ачуы чыкты һәм ул кабат сүз алды. Бу юлы гаепләү рәвеше бөтенләй башка яссылыкта яңгырады:

– Ул урлашмый, – дип башлады сүзен һәм җинаять эскәмиясендә утыручының гомерендә бернәрсә дә урламавын дәлилләрлек мисаллар китергәч, болай дип тәмамлады: – Менә монысы инде бернинди кануннарга да сыймый. Бу җинаяте белән ул безнең бөтен системаны куркыныч астына куя.

Зал озакка сузылган көчле алкышларга күмелде.

Алкышларлыгы да бар иде, чөнки гаепләүче бөтен кешенең күңелендә җыелган дөреслекне ярып салды. Урлашмау – бу илдә иң зур гөнаһ иде. Патшасыннан башлап гади кешегә кадәр һәркем үз ягын каера, җае чыкса-чыкмаса да, үз файдасына умырып калырга тырыша һәм бу иң гадәти хәл булып, яшәү рәвеше булып исәпләнә, системаның нигезен тәшкил итә иде. Хакимияттә утыручылар үзләренә урлашырга җайлы законнар кабул итә, шул законнар нигезендә мөлкәт җыя. Бандитлар шулай баеган кешеләрнең балаларын азгынлык, наркомания, эчкечелек юлына тартып акча эшли. Полиция шул бандитларның хәлсезләнеп яки бөлеп кирәксезгә әйләнгәннәрен төрмәгә яба… Һәм башкалар… Тормыш шул рәвешле бара һәм бу һәркемне канәгатьләндерә иде. Бу җәмгыятьтә урлашмаган кеше – иң зур җинаятьче иде. Адәм үтерү дә җинаять. Ләкин бер кешенең үлеме әллә ни зур югалтуга китерә алмый. Ә урлашмау – ул системаны нигезеннән черетергә, җимерергә омтылу. Син урлашмыйсың, мин урлашмыйм, ул урлашмый… Урлашмаучыларның саны шул рәвешле арта бара. Һәм рәхәтләнеп урлашырга теләгән хөрмәтле гражданнарның эшчәнлеге куркыныч астында кала. Бу илне таркату, идеологик диверсия, рухи террор иде.

Хөкем ителүче үзенең кечерәеп калуын үзе үк сизеп торды. Бетте. Болай булгач, бер өмет тә калмады. Аны, ким дигәндә дә, сәяси җинаятьтә гаепләячәкләр. Ким дигәндә дә, гомерлеккә ябачаклар.

Адвокат хәзер гаепләүчегә каршы төшәргә тиеш кебек иде. Тик ул аны дәвам итте:

– Урлашмавы гына бер хәл әле. Ул бит шәфкатьлелек акцияләре дә оештыра. Әлбәттә, шәфкатьлелек белән шөгыльләнүчеләр сезнең арагызда да бар. Әмма моны һәркем үз мәнфәгатьләре өчен файдалана. Кемдер салым түләмәс өчен, кемдер сәяси өстенлекләр, кемдер үзен рекламалау өчен. Ә бу бернинди шәхси максатларын күзалламыйча, чын-чынлап мохтаҗларга ярдәм итү өчен.

Моны көтмәгән зал тын-тын калды. Ә адвокат шул арада аның бу өлкәдәге эшчәнлеген барлап чыкты. Хәзер инде гаепләнүчегә гомерлеккә төрмәгә ябылу куркынычы буй җитмәслек хыял булып тоелды. Ул, берни дә күрмәскә теләп, күзләрен йомды.

– Үрдә чыгыш ясаучылар китергән дәлилләр бер генә нәрсәне куәтли, – дип сүзен тәмамлады адвокат. – Гаепләнүче – ахмак. Һәм аны төрмәгә ябарга түгел, ә хастаханәгә салырга кирәк.

Бу сүзләрне ишетүгә, халык никтер шаулаша башлады, урыныннан кубып, ишеккә юнәлде. Гаепләнүче кинәт күзләрен ачты. Һәм күңелен шатлыклы уй телде. «Аллага шөкер! – дип уйлады ул, ишеккә атлаган кешеләргә карап. – Аллага шөкер! Ярый әле юньләп эшләгәнем, башкаларга ярдәм иткәнем юк…» һәм елмайды. Хөкем залында түгел икән бит, хезмәт урынындагы чираттагы җыелышта аз гына черем итеп алган икән. Шулай булгач, ничек шөкер итмисең инде?!

Ул арада бер хезмәттәшенең тавышы ишетелде:

– Карале. Арт ягыңа чуан чыкмагандыр бит?

– Юк, – дип елмайды ул. – Ник сорыйсың?

– Җыелыш буена басып тордың ич.

Марат КӘБИРОВ.

ХӘТЕР

Еракта, еллар артында
Моңаеп, еламсырап,
Үткәннәргә үпкә сымак
Бер малай карап тора.
Ул – сугыш вермәсендә
Әтисез калган малай,
Бәрәкәт качкан табында
Ипигә мохтаҗ малай.
Ничекләр итеп юатыйм,
Нинди сүз әйтим аяп;
Кызларга күз төшәр чакта,
Бичара – яланаяк.
Чакырам аны янымa;
Чакырам бүгенемә:
– Туңгансың, әйдә,
җылын, – дим,
Ни хөрмәт күйыйм сиңа?!
Әйдәле, җитеш бәлештән,
Казыннан, йөземеннән…
(Инде ул елларның үчен
Кайтардык йөзе белән!)
Кисән, дим, әнә чөйдәге
Киемнең затлыларын,
Кызларның иң кәттәләрен
Каратыр идең, парин…
Ул миңа карый мөлдерәп,
Тын гына, еламсырап,
Бүгенге рәхәт заманга
Үпкәсе булган сымак.
Нигъмәтләр тулы табында,
Үзара дәшми бер сүз,
Малай чак белән икәүләп
Чәй эчеп утырабыз…

Әхмәт РӘШИТ.

ТАШКА БАСКАН

✓ Тарихка кереп калырга да, чумарга да мөмкин.

* * *

✓ Балда-майда йөзәр өчен бал корты кебек эшләү мөһим түгел.

* * *

✓ Тормыш безнең план белән танышмаган булып чыкты.

* * *

✓ Кыюларга уңыш елмая. Һәм бераздан ыржая башлый.

* * *

✓ Кайда белем алуың түгел, ә нәрсә белүең кызыграк.

* * *

✓ Аз гына күләмдә хәмерне күпме эчсәң дә була.

* * *

✓ Яшәү – түбәнгә илтүче баскыч буйлап югары күтәрелү.

* * *

✓ Куенга ташланмаган кызлар күзгә ташлана.

* * *

✓ «Дөресен әйт!» – дигән сүз тырышыбрак алдарга мәҗбүр итә.

* * *

✓ Йозак тишегендә ике күз очрашты.

3 мәзәк

Бер ир яңа туган баласын теркәтү өчен загска килә.

– Исемегез?

– Вәлиев Гали Мотыйгуллович.

– Анасының исеме?

– Шайтан алгыры, белмим!

– Сез аны чакырганда кем дип эндәшәсез?

– Мин аңа эндәшмим, ә сызгырам гына.

* * *

Анатомия дәресендә укытучы сорау бирә:

– Йөрәк кайсы якта урнашкан?

Вәли кулын күтәрә.

– Йә, әйтеп кара.

– Шуны да белмәскә. Эчке якта, билгеле.

* * *

– Пароль?

– Ракета.

– Уз.

– Пароль?

– Ракета.

– Уз.

– Пароль?

– Танк.

– Юк, ракета. Уз.

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА 8 (917) 851-69-62

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 6043
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 708. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр - сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы